БӘХЕТЛЕ АВЫЛ

Түбән Бәрәскә халкы сүз саен шөкер итә

> 6

БЕЗНЕҢ ТУЙ

Сабан туе безне бер-беребезгә ни дәрәҗәдә якынайта?

> 16

РӨСТӘМ ГАЛИУЛЛИН:

«Казан утлары» – бәхетле журнал»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 81 (28854) | Җомга | 10 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЯШЬ КӨЧ

ҮСМЕРЛӘРНЕ ҖӘЙГЕ ЭШ УРЫННАРЫНДА КӨТӘЛӘР

Җәйне ял итү түгел, акча эшләр өчен көткән балалар да бар. Берәүләр туңдырма сата, белдерү тарата, икенчеләр көтү көтә. Республикада ел саен 10 мең үсмергә вакытлыча эшкә урнашу мөмкинлеге тудырыла. Кесә ягын ким дигәндә 6–7 меңгә, күп дигәндә 30–60 мең сумга кадәр калынайтырга була. Ничек эшлисең бит!

> 15

КӨТЕП АЛГАН БӘЙРӘМ



Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның 2022 елда Сабан туен уздыру уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле татарстанлылар!

Халкыбызның иң яраткан, иң көтеп алына торган ямьле бәйрәме – Сабан туе уңаеннан сезне чын йөрәктән тәбрик итәм!

Ерак бабаларыбыздан бүләк булып, игенченең хезмәтен олылау, кыюлыкта, җитезлектә һәм осталыкта ярышу, гадел бәйге асылын тәшкил иткән бу бәйрәм табигатьнең яшәрүен, татар халкының юмартлыгын һәм кунакчыллыгын гәүдәләндерә. Сабан туе каһарманнарына – авылларның уңганнарына, зирәк һәм олпат аксакалларыбызга, билбирмәс батырларга зур игътибар һәм ихтирам күрсәтәбез. Мәйдан уртасында калкып торган биек, шома багана очында бер-берсенә уралып җилфердәгән төрле төстәге тасмалар шикелле, Сабан туенда да күп гасырлар дәвамында туплана килгән милли гореф-гадәтләребез һәм заманча мәдәни юнәлешләр бергә үрелә бара.

Татарлар өчен Сабан туе – туган нигез белән җанлы бәйләнеш ул. Туган йорт хакындагы җылы хатирәләр, сихри курай моңы сыман, һәркемнең күңелендәге иң нечкә кылларга килеп кагыла.

Безнең заманда ата-бабаларыбыздан килгән туган телебезне һәм гаилә учагын олылау, төрле милләт һәм дин вәкилләренең дус-тату яшәү нигезләрен ныгыту кебек кыйммәтләрне саклау һәм үстерү аеруча мөһим. Сабан туен илебездә яшәүче барлык халыкларның һәм этник берлекләрнең мәдәни үзенчәлекләрен җуймау максатын күздә тотып игътибарлы итеп Россия халыкларының мәдәни мирасы елында бәйрәм итү үзенчәлекле мәгънә төсмере ала.

Быел Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган киң колачлы чаралар уздырылды. Бу тарихи вакыйга татар мәдәниятенә, халкыбызның гореф-гадәтләренә, көндәлек тормышына зур йогынты ясады. Иманлы ата-бабаларыбыздан олы мирас итеп туган җиргә чиксез бирелгәнлек, дини-әхлакый хәзинәләр, бай рухи һәм матди мәдәни ядкәрләр калдырылган.

Сабан туе һәркемгә халкыбызның бай тарихы, мәдәнияте белән якыннан танышу мөмкинлеге бирер, туганнары һәм дуслары белән очрашу-күрешү шатлыгы, якты тәэсирләр бүләк итәр дип ышанам.

Сезгә ихластан күңел күтәренкелеге, бәхет, иминлек һәм тынычлык телим. Бәйрәм мөбарәк булсын!

УЙЛАП КЫНА ЭШ БЕТМИ

Технологияләргә акча кызганырга кирәкми. Республика вузлары, югары мәктәп булудан бигрәк, тикшеренү үзәкләре булырга тиеш. Шул очракта гына эш бирүче оешмалар белән югары уку йортлары арасында ныклы күпер урнашачак. Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе утырышында яңгыраган төп фикерләр шуннан гыйбарәт. Анда Татарстанда стартап-студияләр булдыру турында сөйләштеләр. Утырышта Президент Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

tatarstan.ru

Аңа кадәр республика җитәкчесе Казан дәүләт мәдәният институты базасында оештырылган инжиниринг үзәгендә булды, лабораторияләр эше белән танышты. Рөстәм Миңнеханов аларның эшен югары бәяләде. «Мәдәният институтында күп кенә техник вузларда да булмаган мондый инжиниринг үзәк бардыр дип уйламаган идем», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Вузлар димәктән, утырышта аларның бакчасына шактый таш атылды. Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында бүгенге вазгыятьнең фәнни-техник эшчәнлеккә дә югары таләпләр куюын искәртте. Президент бу уңайда «Университет технологик эшкуарлыгы платформасы» федераль инициативасы эшчәнлегенә тукталды. «Ил икътисады инновацияләрне тиз генә эләктереп ала белми. Бу – аның зур җитешсезлекләренең берсе. Ул исә үз чиратында технологик яңалыкларга сорауны киметә. Платформа укучылар һәм фәнпедагогия тармагы хезмәткәрләрендә эшмәкәрлек белемнәрен ачу һәм үстерү ярдәмендә әлеге киртәне юкка чыгаруны күздә тота», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әлеге программа кысасында уздырылган «Студент стартапы» бәйгесенә килгән гаризалар саны буенча Татарстан студентлары, Мәскәүдән азга гына калышып, икенче урынга чыккан. Әлеге бәйге кысасында Россиядә 50 университет катнашында стартап-студияләр булдырырга җыеналар. 15е инде быел ук пәйда булачак. Шуларның икесе – Татарстанда. Татарстан Инвестиция-венчур фонды җитәкчесе Айнур Айделдинов сүзләренә караганда, аларның һәркайсына 100әр миллион сум акча сарыф ителәчәк.

Республикада эшләячәк стартап-студияләрнең берсе КФУ базасында ачылачак. Биредә студентлар нефть химиясе, биотехнологияләр юнәлешендә яңа проектлар уйлап табачак. Казан илкүләм тикшеренү технология университеты базасында эшләячәк икенче стартап-студиядә исә химия, инженерия, IT-тармакларга өстенлек биреләчәк.

Дөрес, уйлап табылган проектлар белән генә ерак китеп булмый. Аларны тормышка ашыру өчен шартлар, ярдәм, конкрет оешмаларның бу тәкъдимне күтәреп алуы, алар белән кызыксынуы кирәк. Рөстәм Миңнеханов моның өчен республиканың югары уку йортларына югары мәктәп булудан бигрәк, тикшеренү үзәкләренә әверелергә тиеш дип саный. Президент фикеренчә, сәнәгатьчеләр – прагматик кешеләр. Кулга тотып тормышка ашырырлык проект булса, алар аңа һичшиксез алыначак.

– Әмма безнең вузлар тикшеренү үзәге түгел, һәрчак югары мәктәп дәрәҗәсендә булды. Аларның мондый хокукы юк. Моны үзгәртергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Ни өчен эре сәнәгать оешмалары инновацияле эшләнмәләргә заказ бирми? Чөнки бу технология әле сыналмаган. Теләсә кайсы технология сәнәгый яктан сыналган булырга тиеш. Ә моның өчен акча кирәк. Заказ бирүче сәнәгать оешмасы моның өчен акча түләми. Шуңа күрә хөкүмәт технологияләргә акча кызганмаска тиеш. Шуннан башка бернинди сәнәгый суверенитет турында сүз була алмый.

Татарстан Дәүләт заказы агентлыгы башлыгы Яков Геллер фикеренчә, яңа оешачак стартап-студияләргә нинди юнәлештә эш алып барыга кирәклеген ачыклау өчен гади генә кагыйдәне истә тотарга кирәк. «Иң элек республиканың нинди товарларны сатып алып, кайсыларын үзендә җитештерүен ачыкларга кирәк. Шулар арасындагы бушлык – стартап-студияләр өчен менә дигән мәйданчык инде», – диде Яков Геллер.

Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министры вазыйфаларын башкаручы Олег Коробченков исә республиканың фән тармагы белгечләре белән сәнәгатьчеләр арасындагы күперне ныгыту юлларын башкачарак күрә. «Безнең институт, университетларның тәкъдимнәре бар, аларны сәнәгатькә кертеп җибәрергә кирәк дип әйтергә яратабыз. Әмма бу гына аз. Фән җәмәгатьчелеге сәнәгатьчеләргә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, алардан конкрет проблеманы хәл итү өчен, конкрет заказ алырга тиеш. Ике арада хезмәттәшлек шул очракта гына барып чыгачак», – дип саный ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Ипиле төзелеш

Яшел Үзән районында заманча элеватор төзи башладылар. Свияжск төбәкара мультимодаль логистик үзәгендә барлыкка киләчәк элеваторда берьюлы 112,5 мең тонна ашлыкны саклап булачак.

2,4 млрд сумлык проектны «Август-Агро» компаниясе тормышка ашыра. «Свияжск-Зернопродукт» элеваторы су юлына якын урнашкан. Тимер юл да якында гына. Биредә сәгатенә 700 тонна йөк төяп булачак. Нәтиҗәдә «елга –дингез» судносына һәм тимер юл составына ашлык төяү вакыты 10 сәгатьтән дә артмый. Төзелеш берничә этапта уза. Беренче өлеше 2023 елның сентябрендә эшли башлаячак, ә проект 2025 елда тулысынча тормышка ашырылыр дип көтелә. Охшаш элеватор Бөгелмә районында да булдырып килергә мөмкин.

Төзелешне башлау тантанасында катнашкан Президент Рөстәм Миңнеханов «Август» компаниясенең Татарстан белән уңышлы хезмәттәшлек итүен әйтте. 2019 елда «Алабуга» махсус икътисади зонасында «Август-Алабуга» заводы төзелде. Анда үсемлекләрне саклау чараларын җитештерәләр. Моннан тыш, компания республиканың кайбер районнарында заманча авыл хуҗалыгы предприятиеләрен үстерә. «Бүген азык-төлек куркынычсызлыгы мәсьәләсе беренче урында тора. Татарстанда кимендә 4 млн тонна ашлык җитештерергә кирәк. Заманча сыйфатлы саклаудан һәм эшкәртүдән башка нинди дә булса эшчәнлек алып бару кыен», – диде ул. Президент республиканың «Август» агросәнәгать проектларына ярдәм итәчәген дә әйтте. «Без сезнең проектларга җитди мөнәсәбәтегезне күрәбез», – диде ул.

«Август» компаниясе генераль директоры Александр Усков республика җитәкчелегенә проектны хуплавы өчен рәхмәт әйтте. «Татарстанга килгән саен яңа проектлар буенча фикерләр барлыкка килә. Биредә аларны тиз арада тормышка ашырып була. Башка якка борылып карыйсы да килми. Инвесторларга биргән мөмкинлекләр өчен зур рәхмәт. Бүген без башлаган проект республика авыл хуҗалыгы үсешенә үз өлешен кертер, дип өметләнәм», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Свияжск төбәкара мультимодаль логистик үзәгендәге башка объектларда да булды. Әйтик, «KazanExpress» маркетплейсы яңа складның беренче корпусын төзү эшен тәмамлап килә. «Выбор-Поволжье» компаниясе тротуар плиткасы җитештерү заводын төзи. Проектның бәясе –1,8 млрд сум. Президентка үзәкнең үсеш концепциясен дә тәкъдим иттеләр.

Районнарда ни хәлләр?

Зәй

Район биләмәсендә нефть чыгару белән шөгыльләнүче оешманың Директорлар советы карары белән Чыбыклы, Сәвәләй, Гулкин, Төги мәктәпләренә акчалата ярдәм өчен сертификат тапшырдылар. «Максатыбыз – яшь буынны тәрбияләүгә, алар киләчәктә илебезнең терәге булырлык белгечләр булып үссеннәр өчен уңай шартлар тудыруга өлеш кертү. Зәй районында без дүрт авыл җирлегенә караган территориядә эшлибез. Әлбәттә, бу җирлекләрдә яшәүчеләр җир асты байлыкларыннан файда күрергә тиеш», – диде нефтьчеләр оешмасы директоры урынбасары Нәфис Ибраһимов. Сертификатларның суммасы төрлечә: ул оешманың әлеге җирлекләрдә нефть чыгару өлешенә карап билгеләнгән. Акчаны нинди эшкә тотасын мәктәпләр үзләре хәл итәчәк.
(«Зәй офыклары»)

Түбән Кама

15 июньнән Түбән Камада җәмәгать транспортында йөрү бәясе үзгәрәчәк. Автобус һәм трамвайларда шәһәр маршрутларында йөрү бәясе 25 сумнан 28 сумга җитәчәк. Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты пассажир ташучыларның юл бәясен индексацияләү турында гаризасын килештерде. «Бу – мәҗбүри чара», – дип аңлатты район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рафаэль Игътисамов. Электрон юл йөрү билеты алучылар исә элеккеге бәядән йөри алачак. Аларны 1 июльдән сата башлыйлар. Бәя арту бердәм социаль юл йөрү билетын кулланучыларга да кагылмый.
(e-nkama.ru)

Әлки

Район әләме Эльбруста булып кайтты. Тау башына аны әлеге район егете Роман Леонтьев алып менгән. Базарлы Матак урта мәктәбен тәмамлагач, Роман Санкт-Петербург шәһәрендәге Хәрби физик культура институтына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлагач, егеткә шушы вузда «тау хезмәте» белгечлеге буенча укытучы булып эшләргә тәкъдим итәләр. Роман беренче тапкыр Эльбруска 2019 елда күтәрелә. Аннан соң ул ел саен үзенең студентлары өчен тауга менү экспедицияләре оештыра. «Үзебезнең район символын Россиянең һәм Европаның иң биек тавы түбәсенә алып менү хакында күптәннән хыяллана идем. Район җитәкчелеге бу тәкъдимне шатланып кабул итте. Хәзер әлеге әләм район музеенда сакланачак», – ди Роман.
(«Әлки хәбәрләре»)

Әлмәт

Районда ел башыннан 800 нче сабый туган. Нарасыйга Мәрьям дип исем кушканнар. Ул 2 июньдә Регина һәм Артур Саламаевлар гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгән. ЗАГС идарәсе белгечләре бәхетле ата-анага сабыйның беренче документын – туу турында таныклык һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның котлавын тапшырдылар.
(almetievsk-ru)

Киләсе утырыш – 15 июньдә

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының утыз икенче утырышы 15 июньдә узачак. Дәүләт Советы Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде.

Президент Рөстәм Миңнеханов парламентка Олег Коробченко кандидатурасын Татарстан Премьер-министры урынбасары – сәнәгать һәм сәүдә министры вазыйфасына билгеләүне килештерүгә тәкъдим иткән. Шул сәбәпле, утырышның көн тәртибенә Олег Коробченко кандидатурасын килештерү, аның депутат вәкаләтләрен вакытыннан алдан туктату, Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты составын үзгәртү мәсьәләләре кертелә.

Моннан тыш парламентчылар Россия субъектлары – Татарстан белән Чуашстан, Татарстан белән Башкортстан республикалары арасындагы чикләрнең урнашу урынын билгеләү турында килешүләрне раслау мәсьәләсен караячак, Хисап палатасының узган елдагы эшчәнлеге буенча хисабын тыңлаячак. 13 закон проекты беренче укылышта карап тикшереләчәк. Алар арасында – 2021 елга Татарстан бюджетын һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын үтәү турында, оешмалар милкенә салым турында Татарстан законнарына үзгәрешләр кертү хакында закон проектлары һ.б.

Утырыш барышында наркотиклар ясау, сатып алу, саклау һәм сату өчен җәза чарасын катгыйлатуга юнәлдерелгән федераль закон проектын (Татарстан Президенты кушуы буенча әзерләнгән) Дәүләт Думасына кертү буенча Дәүләт Советының закон инициативасын карап тикшерү планлаштырыла.

Президиум утырышында яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов балалар һәм үсмерләрнең җәйге ялын оештыру турында сөйләде. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Президиум әгъзалары, депутатлар һәм башкарма хакимият органнары вәкилләренә балалар иминлегенә игътибар итәргә кирәклеген әйтте.

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының утыз икенче утырышы 15 июнь көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Дәүләт Советы депутатларын теркәү Дәүләт Советы бинасында 15 июньдә 8.00 сәгатьтән башлап хәл ителә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

Киңәшле эш

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Түбән Новгородта Идел буе федераль округы субъектлары дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясе утырышында катнашты.

tatarstan.ru

Алтмыш дүртенче утырыш юбилей утырышына әйләнде – Ассоциация эшли башлаганга быел 20 ел тулды. Фәрит Мөхәммәтшин 2002 елдан бирле аның әгъзасы булып тора. Ул – оешмага нигез салучыларның берсе, ике тапкыр – 2005, 2015 елларда аның координаторы итеп сайланды.

Фәрит Мөхәммәтшинга Ассоциацияне булдыру һәм үстерүгә шәхсән зур өлеш керткән өчен Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиленең Рәхмәт хаты тапшырылды.

«Округның законнар чыгаручылары, Идел буе төбәге субъектлары парламентчылары җитәкчеләренең берлектә эшләве өчен әйбәт мәйданчык булдырылды, – диде Фәрит Мөхәммәтшин журналистларга, Ассоциациянең егерме еллык эшенә йомгак ясап. – Биредә без уңай тәҗрибә белән уртаклашабыз һәм көн кадагына суга торган мәсьәләләрне карыйбыз. Бу юлы без Ассоциациянең алга таба эшчәнлеге буенча үз тәкъдимнәребезне дә җиткердек. Бу эш алга таба да камиллләштерелер һәм ныгыр дип уйлыйм».

Ассоциациянең алтмыш дүртенче утырышында парламентчылар хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү һәм күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру хакында фикер алышты.

ЗАМАНАСЫ НИНДИ – КАРАРЫ ШУНДЫЙ

Бүген бик күп актуаль мәсьәләләр буенча гадәти булмаган карарлар кабул итәр чак. Казанда узган Халыкара Евразия интеграциясе конгрессының пленар утырышында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шулай дип белдерде. Сәясәтчеләр, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре кичәге утырышта яңа шартларда Евразия киңлегендә актуаль берләшү турында фикер алышты.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, быел унынчы тапкыр уздырылучы конгресс дистә ел эчендә шактый үзгәрешләр кичергән. Элегрәк биредә күбрәк мәдәни багланышлар турында фикер алышсалар, соңгы өч елда конгресста сәяси, икътисади яктан берләшү мәсьәләсенә өстенлек бирелә.

Фәрит Мөхәммәтшин конгрессның быелгысын үзенчәлекле дип атады. Ник дигәндә, ул Украинадагы махсус операция шартларында уза. «Безнең илгә каршы күпсанлы санкцияләр кертелде. Алар финанс системасын, тулы бер оешма һәм икътисадның аерым тармаклары эшчәнлеген чикләде, һава юллары, диңгез портлары ябылды. Бүген халыкара мөнәсәбәтләр системасы да тамырдан үзгәрешләр кичерә», – ди парламент башлыгы. Мондый шартларда яңа хезмәттәшләр эзләү, халыкара хезмәттәшлекнең башка юлларын табу, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдә логистик элементларны җайга салуның мөһим булуын да искәртте ул. Парламент башлыгы әйтүенчә, Татарстанның бизнес вәкилләре яңа сәүдә-икътисади элементларне барлый. «Россия төбәкләре арасында беренчеләрдән булып үз алдыбызга ачыктан-ачык максат куйдык, өстенлекле якларыбызны билгеләдек», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент башлыгы фикеренчә, Татарстанда 2030 елга үсеш стратегиясенең дә аерым бүлекләрен яңадан карарга, әлеге документ нигезендә фәнни-технологик үсеш стратегиясен дә булдырасы бар. Бу эшне башкарганда исә республикада яшәүче милләтләрнең бай рухи-мәдәни мирасын истә тотмый мөмкин түгел. «Татарстан Дәүләт Советы депутатлары бу документ эшләнешен үз контроленә алып, сайлаучылар белән очрашулар барышында бу уңайдан фикер дә алыша алыр иде», – ди Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент башлыгы фикеренчә, бүген бик күп актуаль мәсьәләләр буенча гадәти булмаган карарлар кабул итәр чак. Бу урында Татарстанда Евразия фәнни-аналитик һәм мәгълүмат үзәге булдыруның урынлы икәнен дә искәртте ул. «Идел буе округында мондый үзәк урыннарда кадрлар потенциалын көчәйтүгә, белгечләрне Евразия профессиональ челтәренә кертүгә этәргеч була алыр иде», – дип саный Фәрит Мөхәммәтшин.

Россия Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары Александр Бабаков фикеренчә, бүген безнең икътисад ягыннан гына түгел, тарихыбыз, мәдәниятебез белән дә көчле булуыбызны дәлилләр вакыт. «Татарстан бу яктан бик яхшы үрнәк булып тора. Төрле дин, милләт вәкилләренең үзара дус, тату яшәве белән генә түгел, Россияне алга этәргән, әтәрәчәк вакыйгаларда актив катнашуы белән дә игътибарга лаек ул», – диде Александр Бабаков.

Чутлыйсы да түлисе

Татарстанда газлаштыру программасы дәвам итә. Бүгенгә республика халкыннан газ кертүне сорап 14,7 мең гариза кергән. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында «ГазпромТрансгазКазан» оешмасының техник шартлар хезмәте җитәкчесе Артем Алексеев хәбәр итте. Аның сүзләренчә, мөрәҗәгать итүчеләрнең яртысыннан күбесе белән газ кертү хакында килешү төзегәннәр дә инде.

– Республикада 3,1 мең йортка газ кертү өчен торбалар салынды. 700 йорт участогында инде газ бар. Татарстанда бу эшләр буенча төбәк штабы төзелде. Аны Президент Рөстәм Миңнеханов җитәкли, – диде Артем Алексеев.

Инде алдан хәбәр иткәнебезчә, газны капка төбенә кадәр бушлай сузалар. Өйгә керткән өчен үзеңә түлисе була. Газ кертер өчен кешенең кулында шушы йортка һәм җиргә документы булырга тиеш. Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы аша, кәгазьдә тутырып, горгаз, райгаз оешмаларына тапшырырга да була. Гаризада паспорт, СНИЛС мәгълүматларын, телефон номерын күрсәтергә, йортка һәм җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәсен кушымта итеп бирергә кирәк. Кертү вакытын газ оешмасы билгели. Ул кемнәргәдер тизрәк тә булачак. Иң мөһиме – сез яшәгән җирдә газ кертү өчен мөмкинлекләр булу шарт. Әгәр инде мөмкинлек юк икән, газчылар мөрәҗәгать иткән кешегә вакытын үзе билгели. «ГазпромТрансгазКазан» оешмасы белгечләре, бер гариза да кире борылмаячак, дип ышандыра.

Очрашуда субсидия хакында сөйләшмәсәләр дә, исегезгә төшереп үтәбез: кайбер төр категория кешеләр (Бөек Ватан сугышы ветераннары, күпбалалы гаиләләр, инвалид сабый тәрбияләүчеләр) ташламадан кулланырга хокуклы. Алар газ кертү һәм кирәкле җиһазлар алу өчен субсидиягә өметләнә ала. Ярдәмнең күләме 80 мең сумга кадәр җитәргә мөмкин. Әгәр җан башына туры килгән керем 10 мең сумнан түбән булса, бу сумманы тулысынча түлиләр. Җан башына кереме 10–19 мең сум булса, чыгымның 75 процентын каплыйлар.

Субсидия эләкмәүчеләргә исә газны өйгә кертү ким дигәндә 60 мең сумга төшәчәк. Әле моңа газ казаны (котел), исәпләгеч, плитә бәясе кермәгән. Бу хакта Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Лилия Борисова әйтте. Баксаң, әгәр кешеләр өенә газ кертү өчен берәр оешма эшчеләрен ялый икән, алар да базар бәясеннән чыгып түли. «Әгәр «ГазпромТрансгазКазан» оешмасы аша бу эшне башкарырга теләсә, аларга тарифны без куябыз. Исәпләп чыгардык. Иң арзан дигәне дә 60 мең сумга төшә, – ди Лилия Борисова. – Газны ике төрле итеп кертеп була. Беренчесе – җир өстеннән, икенчесе – җир астыннан. Бәясе нинди торба куллануга карап та үзгәрә. Әйтик, җир астыннан кергәндә полиэтилен торба кирәк икән. Җир өстендәгесе корычтан булырга тиеш».

Лилия Борисова, бәяләр үзгәрергә дә мөмкин, ди. Әмма шунысы ачык: газлы буласы килгән кешенең кесәсендә 100–120 мең сум акчасы әзер ятарга тиеш.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

✓ Татарстанда газлаштыру дәрәҗәсе **99,5** процентны тәшкил итә. Республикада **1,5** миллион фатир һәм йорт газга тоташтырылган.

✓ Ел саен **19** меңнән артык фатир һәм йортка газ кертелә.

✓ Программа буенча быел республикада **8534** йортка газ кертелергә тиеш.

✓ **2023** елда **9270** йортка зәңгәр ягулык килер дип көтелә.

Әйтеп кенә бактым

Хата

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Телебезне баету, аның камиллеген саклау, кулланылыш даирәсен киңәйтү өчен тырышабыз үзе, төрле юлларын эзләп баш ватабыз. Мәсәлән, элмә такталардагы хаталарны табу буенча бәйгеләр дә оештыра башладык. Хаталарны иң күп тапканнарга кыйммәтле бүләкләр вәгъдә иттек. Әмма күңелдә авыр тойгылар калды. Ни өчен соң әле без һаман да нәтиҗә белән көрәшәбез?

Татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү турында закон да кабул иттек. Әмма закон гамәлгә керә алмый азаплана. Моңа кем гаепле? Шактый ук дәрәҗәдә үзебез. Шул ук элмә такталарны гына алыйк. Хаталар белән язарга безгә Мәскәү кушмый бит!

Күптән түгел Азнакайга барып кайттым. Юл өстендәге Сарсаз авылы уртасында матур гына күрсәткеч такта тора. Анда «Аръяк елгасы» елгасы» дип язылган. «Аръяк елгасы» дигәне генә җитми микәнни? Бу «аның исеме – Рәшит исемле» кебегрәк булып чыга инде.

Казанның 3 нче троллейбус маршрутында «Остановка по востребованию»не «Сорау буенча тукталыш» тукталышы» дип игълан итәләр. Телне кадерсезләү шушы була инде ул. Ана телебезне үзебез чүплибез, пычратабыз, матур яңгырашын юкка чыгарабыз.

Күрсәткеч такта, элмә такталардагы кердәле-киттеле сүзләр һәм сүзтезмәләр бит ялгыш җибәрелгән хата түгел, хаталы язу системага әйләнде. Әгәр хата системага әйләнә икән, моны закон бозу дип бәяләргә мөмкин түгел микән дигән шик бар. Әгәр шулай икән, димәк, закон бозучы җавапка тартылырга тиештер.

Хакимият органнарында элмә такталар өчен җавап бирүчеләр бар. Әгәр алар рус кешесе икән, татар белән киңәшмичә калмыйлардыр. Заманында районнарда элмә такталар буенча хәтта тәрҗемәчеләр булдыру турында да сүз чыккан иде. Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында хаталарны төзәтергә ярдәм итү өчен «Халык контроле» дә оешты. Белүемчә, институт шактый зур эш башкарды, әмма хаталар кала бирә. Алай гына да түгел, хаталы язулар арта тора.

Галимнәр әйтүенчә, кайбер элмә такталардагы хаталарны төзәтеп булмый. Сүздә татар хәрефләре булса, рус телендә транскрипциягә килгән хәрефне куялар үзе. Рус кардәшләргә татар алфавитындагы берничә хәрефне әйтү, үзләштерү кыен, ахрысы, шуңа күрә, мәсәлән, авыл исемнәрен ничек кенә язып бетермиләр.

Беркөнне «ВТ» кызлары бер районның бер авылы исеме ничек языла икәнлеге турында баш ватып утыралар иде. «Риман абый, синең булмаган районың юктыр, фәлән районда шундый авыл бармы?» – дип сорадылар. Кайсы район һәм авыл турында сүз барганы онытылган, шуңа күрә «фәлән» дип язам. Менә шул кызлар әйткән фәлән авылны белмим булып чыкты.

Административ бүленеш китабын да актарып карадык, андый авылны таба алмадык. Шуннан районга шалтыраткан идек, ул авыл бөтенләй башкача атала икән.

Элмә такталардагы хаталарны эзләү, бер уйлаганда, вак эш кебек. Әмма шул ук вакытта без ана телебездән үзебез көләбез, аны санга сукмыйбыз булып чыга, татарга ярамаган тагын, янәсе.

Шуны уйлап куйдым: әгәр русча атамалар хаталар белән язылса, киң җәмәгатьчелек моңа нинди күз белән карар икән? Белмичә яки белә торып кылынган хаталар өчен кемдер җавап бирергә тиештер бит инде, диясе килә.

АК ТАРТМАЛАР ИКЪТИСАДЫ,

ЯКИ СӘНӘГАТЬ ИПОТЕКАСЫННАН НИЛӘР КӨТӘРГӘ?

Бу юлларның авторын тормышның гел караңгы якларын яктыртуда гаепләргә теләүчеләр бар. Фанфаралар кагарга була ул, әлбәттә. Тик «бал, бал» дип күпме генә кабатласак та, авызда бал тәме барлыкка килми.

tatarstan.ru

Аннан соң автор язмаларына нигез итеп һәрвакытта да федераль хөкүмәт газетасы «Российская газета» материалларын алырга тырыша. Болай эшләү ышанычлырак, бердән, «фейк» мәгълүмат дип табылырлык нәрсәләрдән азат итә. Рәсми фикер рәсми фикер инде ул, кайвакыт ялгыш булып чыкса да, аның өчен берәүне дә гаепләмиләр. Икенчедән, федералларда мәгълүмат мулрак, чөнки алар төп һәм беренче чыганаклар белән эш итә. Өченчедән, вазгыять катлаулы һәм аны бизәп күрсәтергә тырышу тагын да катлауланууга китерә. Мәскәү дә объектив рәвештә авырлыкларны таный. Әйтик, менә Владимир Путин иң соңгы чыгышларының берсендә: «Күп кенә тармаклар, аерым алганда, кара металлургия кыска сроклы перспективада җитештерүнең сизелерлек кимү хәвефе турында сигнал бирәләр», – дип игълан иткән икән, без ул объектив чынбарлыктан качарга тиешмени?

«Российская газета» үзенең бу атнадагы чәршәмбе санында (автор чәршәмбе көнне әзерли материалын) «Куда исчезли краски с упаковок молока и соков и каких еще ограничений ждать» дигән күләмле язма бирде. Ул менә мондыйрак юллар белән башлана: «Производителям не хватает красок. Такие временные трудности с поставками отдельных ингредиентов российские предприятия по выпуску повседневных товаров еще будут испытывать в течение нескольких месяцев, пока не найдут новых поставщиков. Исключение составляют разве что высокотехнологичные товары. Здесь импортозамещение займет точно не месяц, не полгода и не год». Бик караңгы фараз инде, әйеме? Югары технологияле товарлар белән бәйле кыенлыкларның берничә ел барачагын әйтә. Болар – электроника, автомобильләр, очкычлар… дигән сүз. Безнең тормыш соңгы елларда алар белән шулкадәр тыгыз бәйләнде: гаджетларсыз, автомобильләрсез яшәүне күз алдына да китерә алмыйбыз.

Югарыдагылар, мәскәүлеләр, кул кушырып ятмыйлар, әлбәттә, кыенлыклардан чыгу юлларын актив эзлиләр. Безнең фәкыйрьлек бит акчасызлыктан түгел, акча капчыгы өстендә утырган килеш товар да, технологик җиһазлар да, технологияләр дә сатып алудан мәхрүм калып интегүдән. Соңгы икесен хәзерге ашкын темпларда үсүче технологик җәмгыятьләрдә тиз генә булдыру мөмкин түгел, бикләнеп яшәгән хәлдә бөтенләй дә мөмкин түгел. Изоляциядән чыгу юлларын эзләү – сәясәтчеләр һәм дипломатлар эше, без аларның эшенә кысыла алмыйбыз. Әмма кәгазь тартма буярлык төсле буяулар да таба алмаслык хәлдә калмас өчен, киләчәктә ниләр эшләргә дигән сорауга бергәләп җавап эзләргә була.

Ни өчен шөрепләргә кадәр чит ил икътисадларына бәйле булдык дигән сорауның җавабы бар һәм бик гади. Бердән, табигый ресурслар инәсендә бик каты утырдык. Үзебезнекен җитештерүгә бер дә ихтыяҗ булмады, читтән сатып алу арзангарак төште. Икенчедән, бер Россия генә түгел, технологик яктан алга киткән Япония һәм Кытай да, Көнбатыш дәүләтләре дә шулай яши, соңгы продуктны чит илләрдән алган комплектлаучы детальләрдән җыялар. Аерма шунда гына: алар комплектлаучыларның бер өлешен, бөтен дөнья өчен дип, үзләрендә җитештерәләр. Бүгенге глобаль икътисад ул аркау һәм буй җепләр аралашып беткән тукыманы хәтерләтә. Җепләрнең кайсын гына алсаң да, тукыма тарала да төшә. Безнең икътисадның ни өчен авыр хәлдә калуын аңлыйсыздыр инде шуннан соң.

Икътисади бәйләнешләрнең өзелүе Украина конфликтыннан күптән алда, хәтта Ковид-19га кадәр үк мәйданга чыкты. АКШта Президент сайлавында Трампның җиңүе зур җимерелүнең башы булырга тиеш иде. Мин 2016 елда Трамп җиңүгә үк «Трамп революциясе» дигән язма бирдем һәм газетада олигарх-президентның глобаль капитализмга кабер казучы буларак мәйданга килүен игълан иттек. Аннан бераз гына алдарак Бөекбритания Евросоюздан чыга башлагач, «Брексит артында ни ята?» дигән язмада: «Дөнья кайчандыр СССР таркалган, социалистик система җимерелеп төшкән чактагыдан да хәтәррәк чорга кереп бара», – дип белдердек һәм кредитларга нигезләнгән финанс капитализмының җимереләчәген бер дә курыкмыйча игълан иттек. Безнең архивта тагын «Доллар белән бәхилләшү» (Россиядә бүгенге вазгыятьнең туачагын, Көнбатыш – Россия конфликтының котылгысызлыгын 2017 елда фаразлаганбыз), «Кризисны кәгазь язып җиңү» (федераль хөкүмәт планнарының тормышка ашмыйча җимерелеп төшәчәген әйткәнбез берничә ел элек) һәм теманы яктырткан башка күп язмалар бар. Әйтеп карагыз: безнең интуиция ялгыша, сиземләвебез дөрес түгел дип.

Федераль хөкүмәт Рәисе Михаил Мишустин 26 майдагы утырыштан соң берничә мөһим әмер бирде. Бу язмада без шуларның икесенә генә кагылабыз. Беренчесе – Минпромторг, Минфин һәм Минэкономразвития дип аталган өч федераль министрлыкка сәнәгать ипотекасы дип аталган өстенлекле ипотеканың параметрларын эшләп гамәлгә кертеп җибәрү. Җитештерүчеләр девелоперлардан җиңел генә җитештерү мәйданнары сатып ала алсын өчен хезмәт итәргә тиеш бу чара. Икенче төрле әйткәндә, девелоперлар индустриаль парклар төзиләр, ә җитештерүчеләр арзанлы банк кредитына шуларны сатып алалар да кирәкле станокларны урнаштырып, импортны алыштырачак товарларны штамплый башлыйлар.

Икенче чара – Финанс министрлыгы АО «МСП Банк» дигән банкның капиталын бюджеттан акча бүлеп үрчетә. Бу банк эшмәкәрләргә өстенлекле ставка белән кредитлар бирергә тиеш.

Нәрсәдер җитештерү өчен финанслар кирәк һәм хөкүмәт җитештерүчеләргә акча агымын юнәлтеп дөрес эшли, билгеле. Әмма гафу итә күрегез инде: югарыда әйтелгән финанслау ысуллары яхшы нәтиҗәләргә китермәячәк. Аның беренчесен бизнес-омбудсмен Борис Титов ТАСС агентлыгына ясаган белдерүендә тәнкыйтьләп өлгерде инде. Без ниятнең ни өчен уңай нәтиҗәләргә китермәячәген дәлилләргә тырышырбыз. Без – дилетантлар, билгеле, әмма калькулятор белән эш итә беләбез. Аннан, соңгы ике елда автор төзелеш белән мавыга һәм ул кичергән кыенлыкларның төп сәбәпчесе – өстенлекле ипотека. Ипотека булмаса, гомумән йорт төзү күпкә арзангарак чыгар иде. Аннан соң глобаль капитализм кризисының төп сәбәбе – процентлы кредитлар бит инде. Кредит биреп (өстенлекле булса да), икътисадны җанландыру туберкулезны диабет белән дәвалауга охшаган. Күз алдыбызга китерәбез әйдә: сәнәгать предприятиеләре өстенлекле кредит алып девелоперларга күчемсез милеккә заказ бирделәр, ди. Соңгылары нишлиләр? Ихтыяҗ арту сәбәпле, бәяләрне күтәрәләр. Бу котылгысыз. Бәяләр болай да тешли торган югары әле. Тагын бәя өстәгәч, бизнес күрәчәк: сатып алынган мәйданда нәрсәдер җитештерү алтын бәясенә төшәчәк. Әле тагын җиһазлар да кирәк бит, аларын да процентлы кредитка аласы һәм соңыннан процентлар түләп җәфаланасы.

Вазгыятьтән чыгуның юлы бар. Россия глобаль капитализм белән кендеген өзәргә мәҗбүр булды бит инде. Доллар безнең өчен генә фантикка әйләнде, икътисади бәйләнешләр чылбырыннан безне көчләп өзделәр. Шулай булгач, рибачы банклардан да баш тартырга һәм инвестицион банклар челтәренә күчәргә иде. Банк бу очракта кредит бирми, ә теге яисә бу проектны финанслый, табыш – булса уртак, югалту – булса уртак. Берәү дә процент түләми. Менә бу очракта банкирлар җитештерү мәйданының сыйфатлы һәм арзанлы булуын кайгыртачак та инде. Девелопердан сатып аламы ул аны, үзе төзиме, исәпләп-үлчәп эш итә. Финансчылар да үзкыйммәтнең түбән булуын кайгырта ягъни. Соңгы продуктның сыйфатлы һәм көндәшлеккә сәләтле булуы өчен дә борчылалар. Белгечләр хәзерләү һәм аларга түләү системасы тамырдан үзгәртелеп корыла, чөнки шуннан башка технологик продукт эшләү мөмкин түгел. Мәгариф реформалары менә шулай тормышка ашырыла ул. Депутатларның амбицияләренә нигезләнеп түгел. Партнерлык икътисады дип аталган икътисад мәйданга килә. Ул мәйданга килсә, хөкүмәт импортны алыштыру программалары төзү белән мавыкмый инде, социаль программалар белән генә шөгыльләнә. Бизнесны тикшерүче күпсанлы чиновниклар армиясенең дә кирәге калмый. Россия шундый икътисадның флагманы була алыр идеме? Була алыр иде. Булачакмы? Гафу итегез, юк. Монысы башка тема инде аның.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

vk.com

КЕСӘГӘ КАРАП

Бәяләр арту туктады, инфляция контрольгә алынды, валюта белән вазгыять – даими. Бу хакта Россия Президенты Владимир Путин икътисад буенча киңәшмәдә хәбәр итте. Ил башлыгы сүзләренчә, бәяләр белән вазгыять тотрыклыланды.

Мәгълүм булганча, соңгы берничә айда барлык төр товарларга да бәяләр котырып артты. Ләкин бу юлы Владимир Путин халыкның күңеленә хуш килә торган хәбәр җиткерде.

– Инфляцияне контрольгә алдык, – диде ул. – 27 майга еллык күрсәткеч 17,4 процент тәшкил итте. Шул ук вакытта майның икенче яртысыннан башлап, бәяләр үсеше бөтенләй тукталды. Хәзер инфляция ноль дәрәҗәсендә.

Шулай ук хакимиятнең уңай һәм тискәре якларын күз алдында тотарга һәм теләсә нинди үзгәрешләргә вакытында реакция белдерергә тиешлеген искәртте.

Президент үз чыгышларында һәрвакыт куллану ихтыяҗын арттыру турында әйтә килә. Бу юлы да әлеге мәсьәләне читләтеп узмады.

– Майда, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, ваклап сату күләме 5,4 процентка арткан. Ләкин чынлыкта, инфляцияне исәпкә алып, ул кыскарды, – дип билгеләп узды Владимир Путин һәм ихтыяҗны арттыру өстендә эшләргә, халыкның керемен күбәйтүне тәэмин итәргә, бизнеска өстәмә чаралар һәм кредит ресурслары тәкъдим итәргә кушты.

Росстат мәгълүматларына күз салсак, бәяләр артуның иң югары ноктасы мартка туры килә. Купчелек төр товарларга бәяләр 26 процентка арткан. Бәяләр апрельдә дә тик тормаган, ләкин узган ай белән чагыштырганда, үсеш темпы бермә-бер кимегән. Бер ай эчендә товар бәяләре 1,5 процентка өскә үрмәләгән. Белгечләр алып барган анализ нәтиҗәләре исә майда бәяләрнең үсмәвен күрсәткән. Росстат әйтүенчә, мондый хәл узган елның августыннан бирле күзәтелмәгән. Алай гына да түгел, «куллану кәрҗине» апрель белән чагыштырганда, хәтта 6 процентка кимегән. Ә 14–20 май аралыгында куллану бәяләре 0,02 процентка кимегән.

Шулай итеп, соңгы берничә атнада яшелчә (кыяр, кәбестә, помидор, чөгендер, кишер), йомырка һәм шикәр хаклары төшкән. Ә менә суган, бәрәңге, алма, банан бәяләре арткан. Шулай ук кер юу порошогы, шәхси гигиена предметлары һәм шырпыга да хаклар күтәрелгән.

КФУның идарә итү, икътисад һәм финанслар кафедрасы мөдире Игорь Кох фикеренчә, чыннан да, инфляция темплары киму билгеләре бар. Март һәм апрельдә күзәтелгән бәяләр арту хәзерге вакытта туктап тора, ди ул.

– Ул вакытта бәяләрнең шулай котырып артуына рубльнең төшүе һәм базардагы башка факторлар йогынты ясаган иде. Хәзер андый хәл күзәтелми. Моннан тыш, бәяләр төшү яки артмау сезонга бәйле. Гадәттә, бу чорда яшелчә, җиләк-җимеш һәм сөт продуктлары хаклары төшә. Бу да инфляциягә үз йогынтысын ясый, – дип аңлатты Игорь Кох.

Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров журналистларга хәбәр итүенчә, якын араларда республикада икмәк бәяләре артуы да көтелми.

– Әлегә бездә икмәк бәяләре элеккечә саклана. Якын арада бәяләр артуны көтмибез, – диде ул.

Аның сүзләренчә, бүген икмәк пешерүчеләр өчен федераль һәм республиканың ярдәм чаралары гамәлдә. Республикада бу максатларга 300 млн сумга якын акча бүлеп бирелгән.

Шул ук вакытта белгечләр россиялеләрнең азык-төлек кәрҗине үзгәрүе турында хәбәр итә. Россия Хөкүмәтенең агросәнәгать комплексы департаментының элеккеге җитәкчесе, икътисад фәннәре докторы Леонид Холод сүзләренчә, россиялеләр иттән баш тартып, күбрәк ярма һәм яшелчә ашый башлаган. Быелның маенда ит, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 2,6 процентка азрак сатылган.

– Кайбер товарларга бәя күтәрелгәч, аларга сорау кими. Алар сыгылмалы дип атала, – дип аңлата белгеч. – Ә кайбер товарларга бәя артса да, ихтыяҗ кимеми. Тавык ите менә шундый товарлар исемлегенә керә иде. Ләкин быел хәтта аңа да сорау кимеде. Бу исә халыкның кереме шактый кимүне аңлата. Кешеләр камыр ризыклары һәм гади яшелчәләр ашауга күчә.

Икътисадчы билгеләп узганча, куллану кәрҗиненең алга таба ничек үзгәрүе икътисад үсеше белән бәйле. «Соңгы вакытта кыйммәтле азык-төлеккә сорау кимеде, – дип нәтиҗә ясый Леонид Холод. – Бу – җиләк-җимеш, кыйммәтле колбаса, сыер ите һәм сыер итеннән ярымфабрикатлар. Шулай ук кыйммәтле сөт продуктларын куллану да кимеде».

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сәяси сәгать

СӘЯСӘТ БЕЛГЕЧЕ МАРАТ БӘШИРОВ:

«Кеше гомере кадерлерәк»

Без әле кая барабыз? Дөньяда ниләр бар? Бу сорауларга җавапны сәясәт белгече Марат БӘШИРОВ белән эзлибез.

:: Марат әфәнде, махсус хәрби операциянең кайчан бетәчәге турында көн саен диярлек яңа фикерләр ишетелә. Бу хакта сез ни уйлыйсыз?

– Операцияне тәмамлау вакытына караганда солдатларыбызның гомере әһәмиятлерәк. Безнең өчен иң мөһиме әнә шундый карарга килү. Шуңа күрә операциянең тәмамлану вакыты турында гомумән ниндидер фаразлар ясау ягында түгел мин. Нинди максатларга ирешәчәкбез? Югалтулар, яраланучылар азрак булсын өчен нинди чаралар күрелә? Әлбәттә, хәрби максатлар да бар. Әмма кешеләрнең гомерен саклап калырга кирәк. Иң мөһиме әнә шул. Ашыгасы җир юк. Вакыт безнең файдага эшли.

:: Операция тәмамлансын өчен ике кешенең утырып сөйләшүе кирәк дигән фикер дә еш ишетелә. Ә Россиянең тышкы эшләр министры Сергей Лавров фикеренчә, Зеленский Путин белән исеме өчен генә очрашырга тели. Гомумән, мондый очрашу узарга мөмкинме?

– Берничә көн элек яклар арасында һәлак булган кешеләрнең мәетләрен алмашу булды. Димәк, ниндидер элемтәләр бар. Хәтерләсәгез, Истанбулда узган очрашуда Россия вәкилләре каршы якка үз таләпләрен җиткерде инде. Киев дәшми икән, димәк, бу хакта барыннан да бигрәк Вашингтонда сөйләшергә теләмиләр. Моны шулай дип аңларга мөмкин. Чөнки «Украина кейсы» АКШка, төгәлрәк әйтсәк, Байден әфәнденең Демократия партиясенә конгрессны контрольдә тоту өчен көрәшкәндә кирәк. Аларда быел 8 ноябрьдә сайлау уза. Әлегә демократларның өстенлеге бар, әмма ул бик тә тотрыксыз. Украина мәйданында җиңелү демократларның тавышын киметергә мөмкин. Барысы да республикачылар партиясенә уңыш юрый. Украинаның җиңелүе ахыр чиктә Байденга карата импичмент игълан ителүнең башы булырга мөмкин. «Украина кейсы»ның асыл мәгънәсе әнә шуннан гыйбарәт.

:: Соңгы арада Украина портларында җыелган ашлык турында сүз күп булды. Каршы якта Россияне хәтта дөньяда ачлык китереп чыгарырга тырышуда гаепләүчеләр дә бар...

– Россия Украинага ашлык чыгаруга комачау итми. Киресенчә, моның өчен ниләр эшләргә кирәклеген тәкъдим итә. Украинада сакланучы ашлыкның зур өлеше сатылган инде. Аның өчен алар акчасын да алган. Шуңа күрә җаваплылык та – Киев ягында. Әмма Россия бу хәлне диңгезне, барыннан да бигрәк Одесса тирәсендәге яр буе турында сүз бара, минадан чистарту өчен файдаланыр дип куркалар. Шул ук вакытта быел җыел аласы ашлыкны да каядыр куярга кирәк. Элеваторда сакланучы ашлык инде тәэп озатылган булырга тиеш иде. Ә хәзер яңа уңышны урнаштырырга кирәк.

:: Инфляция контрольгә алынды, бәяләр артудан туктады, эшсезлек күрсәткече иң түбән дәрәҗәгә төште. Мондый хәбәрләрнең асылы нидән гыйбарәт? Россия икътисады яңа шартларга яраклаша алдымы, әллә бу сүзләрне сәяси белдерү буларак кабул итәргәме?

– Саннардан беркая да качып булмый. Инфляция күтәрелү булды, ә хәзер тукталды. Бәяләр артуны үз кесәбездә тойдык. Шул ук вакытта дәүләт халыкның иң аз якланган катлавына ярдәм итү чараларын эзли. Моның өчен акча да бар. Ә бу бик мөһим. Әмма шунысын да онытырга ярамый: махсус хәрби операция башланганга әле 3 айдан аз гына күбрәк вакыт узды. Миңа калса, икътисадка кагылышлы ниндидер нәтиҗәләр ясарга, ничек яшәячәгебезне, бәяләрне, башка күрсәткечләрне фаразларга иртәрәк. Моның өчен ел ахырын көтәргә кирәк. Үзгәрешләр булырга мөмкин әле.

:: Бу атнада без Россия көнен билгеләп үтәбез. Быелгы вакыйгалар бәйрәмнең мәгънәсен аңларга этәрәме?

– Үзебез бик төрле булсак та, бер илдә ничек яшибез? Ил тирәсендәге вакыйгалар безгә менә шул мөһим сорауга җавап эзләргә мөмкинлек бирә.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

РӘХӘТ БӘХЕТ

ТҮБӘН БӘРӘСКӘНЕҢ ЯШЬНӘП ЯШӘВЕНЕҢ СЕРЕ НИДӘ?

«Коммунизм утравы» булып, гөрләп яшәгән салаларны барлауны дәвам итәбез. Бу юлы журналист сукмагы Әтнә районына барып тоташты. Төгәлрәге, Түбән Бәрәскә авылына. Даны таралган, Совет юлбашчысы исемен йөрткән колхоз, җир кадерен-тәмен белгән кешеләр, сала тормышын сайлаган яшь гаиләләр белән танышып, авылның киң, ямьле урамнарын урап кайттык.

Автор фотосы

Уртак колхоз

Колхоз авылны яшәтеп тә, яшәртеп тә, һәрьяктан тәэмин итеп тә тора. Бар булганы – бергә, югы – уртак. Әтнәнең «Ленин» исемендәге нәселле терлек заводында мөмкин хәл бу. Аңа Түбән Бәрәскә, Бәрәзә, Өшкәтә авыллары керә. Эшлә генә, туган ягың, гаиләң, авылың дип яшә генә, шартларын тудыралар. Колхозы булгач, бирелдә әле дә нәрәт җыела дигән сүз инде.

«Китапта сөйләнгән коммунизм сездә икән», – дибез Илгиз Вилдан улы Хәйруллинга. Ул инде бу сүзләрне безнең авыздан гына һәм бер генә мәртәбә ишетмәгәндер. Ә без кабатладык. Сораштык та, тагын бер кат сокландык та. «Ленин» белән җитәкчелек итүенә 32 ел икән инде. Үзебезчә яратып әйтсәк, колхоз арбасын тартучы тырыш эш аты ул. «Эшләр барамы соң?» – дигән сорауга да, шөкер, дип кенә тора хуҗа. Без авылга кунак булып төшкән вакытта чәчү эшләре гөрләгән мәл иде.

– Авыл хуҗалыгы тармагы – шахмат уены ул. Шундый кызыклы! Ясыйсы адымыңны бер генә түгел, өч адым алдан уйларга кирәк. Табигать кешегә яраклашмый, без яраклашырга тиеш. Шөкер, моннан берничә дистә еллар булган кебек, эчүче кешеләр юк, – ди Илгиз әфәнде.

Чәчүдә дә, фермада да бер генә дә ялкап эшләүче хезмәткәрләре юк икән. «Барысы да – үзебезнеке. 250 колхозчыбыз бар. Байлык бит бу!» – ди Илгиз Хәйруллин.

«Ленин» колхозы буенча уртача хезмәт хакы – 34 мең сум. Сыер савучылары 40–45 мең сум алып эшли. Акчаны хезмәтенә күрә артыграк түләгән чаклар да була. Монда инде кешенең тырышлыгыннан да тора.

Сөт тапшыру буенча башкалар кызыгырлык саннары бар. Бу юнәлештә генә дә халыкка гомумән алганда 6 млн сум күләмендә керем килә. Аена берничә йөз мең сум табыш алучы гаиләләр дә дистәдән артык. Әмма сөтнең литрын ничә сумнан тапшырганнарын Илгиз Вилдан улы сер итеп сакларга кушты. Сыйфат югары булса, зур табыш алырга бик мөмкин, кыскасы. Ә алар сыйфатка бик зур таләпләр куя.

Колхозны уртак дип әйтергә ярата ул. Һәм һәр салада колхозлар булырга тиешлеген дә искәртә. Гомумән, стимул, теләк булганда, кешене кызыксындыра белгәндә, күмәк эшләүнең файдасы булуын да, табыш алуны арттырырга мөмкин икәнен дә дәлилли җитәкче.

Колхоз, кирәк икән, техникасын, терлек азыгын, хәтта шәһәргә барыр өчен җиңел машинасын да бирен тора. Мәчет, мәктәп, клуб төзелешенә акчалата ярдәм итә. Кыскасы, кул кулны юа дигәндәй, авыл – колхозны, колхоз авылны тулыландырып көн күрә.

Юлдашыбыз Сәрия Хәйруллина авылны күрсәтә. Төзек, матур, юллы, сулы, газлы, кыскасы, бар нәрсәсе булган салаларны күрү куандыра. Шуңа өстәп, бай тарихлы! Сүз уңаеннан, Сәрия ханым авыл тарихын барлау, шәҗәрәләр төзү белән дә мавыга. Яшеллеккә күмелеп утырган кыр-болыннары күпме. Авыл күрке – таш мәчетләре бар. Чишмәләре төзек. Авылда яшәүчеләрнең бик күпләрендә сыер саны бердән артыграк.

Авылның бер урамына килеп җиткәч, Сәрия ханым төзек йортларга төртеп күрсәтә. «Хәкимуллиннар бу. Өч уллары да авылда калды. Бер урамны тутырып, гөрләтеп, үз куышларында яшиләр. Алар – авылның чын фанатлары», – ди.

Гаилә башлыкларын очрата алмасак та (эш кызган мәл бит!), хуҗабикәләрнең хәлен белешеп чыктык. Хәкимуллиннарның төп нигезендә – унышар сыер, хәзер балалар да биштән кимне асрамый.

– Шәһәрдә яткачы, монда рәхәтләнеп эшлибез. Авылыбыздагы шартлар каланыкыннан ким түгел. Без кирәк җиргә йөреп торабыз. Үкенмибез. Бәхетле авылда яшибез, – диләр Миләүшә белән Рәзинә.

Җир кешеләре

Гадәттә, сәфәр чыккан саен, авыл җирендә яшәп, шөгылен кәсеп итүчене эзлибез, кул остасы, берәр һөнәргә хирыс кеше юкмы, дип сорашабыз. Бу юлы да искәрмә ясап тормас идек, әмма салада андыйларны табып булмады. Кәсепләре – җир эше. Хәер, колхоз эш белән тәэмин итеп торгач, ниндидер өстәмә мавыгу кирәкмидер дә инде ул. Шуңа да без кыр машиналары гөрелтесен ишетеп, шунда юл алдык. Җир кешеләре белән аралашырга. Аз сүзле, әмма үтә дә тырыш кешеләрне күрергә.

Әнәс Хәйруллин 7 ел агроном булып эшли. «Быелгы чәчү иң авыры булгандыр. Башка елларда алай ук булмый торган иде. Сузылды, яңгыры да яуды. Тыныч күңел белән каршы алган җәй юктыр. Һәр эштәге кебек, агроном хезмәтен дә күңелең белән бирелеп башкарырга кирәк. Эшнең дәрте, рәхәте, басуның фәлсәфәсе бар», – ди ул.

Тамырлары белән шушы авылга берекккән ул. Әтисе дә гомере буе колхозда хезмәт куйган, әнисе алдынгы сыер савучы булып эшләгән. Әнәс абый кечкенәдән үк комбайнер ярдәмчесе булып, кул арасына кереп үскән. «Авылда калуым дөрес булган», – ди җир кешесе.

Инде хәзер үзе дә гаиләле. Хатыны да, Казан кызы булса да, салага кайтып төпләнүдән курыкмаган. 4 бала үстерәләр. 8 ел каенана-каенаталы йортта да яшәгәннәр, зур йорт җиткереп, башка чыкканнар.

– Мал-туар да асрыйбыз, 4 сыерыбыз бар. Хатынга, шаяртып: «Монда кайтып, сыер саварсың дип бер дә уйламаган идем» – дим. Елмая гына! Минем алда авылда калыргамы-юкмы дигән сорау тормады. Балаларны да әллә ни үгетләмибез. Әмма авыл эшен белеп-күреп үскәч, җиргә тартылыр дип уйлыйбыз. Олысы театр училищесында укый. Уртанчы улыбыз шулкадәр эшсөяр. Берничә ел комбайнер ярдәмчесе булып эшли, – дип сөйли эш вакытыннан азга гына бүленеп Әнәс абый.

Раил Галләмов үзенең тормышын авылдан башка күз алдына да китерә алмый. Шушы сала егете бәхетен эзләп читтә йөрмәгән, монда башлы-күзле, эшле-ашлы булган. Хатыны – укытучы, үзе – кыр уңганы.

– Әй, Казанда торып карадым ла мин. Авыл хуҗалыгы институтының механика факультетын бетергәч тә, бер ел калада эшләдем. Әмма туган җиргә кайттым, – ди ул. – Эштән куркып яшәп булмый. Авыл җирендә туып-үскәч, техника белән яшьтән үк дус булгач, сала тормышы үзенә тарткандыр инде, дим. Бала вакытта комбайн, тракторда йөрдек. Классташларның, курсташларның кайсылары шәһәрдә калды. Һәр кешенең үз урыныдыр. Минеке – авылда. Язын, җир шәйләнә башлауга чыгып китәбез, кара көздә, кар яуганчы йөрибез инде. Җирдә эшләгәч, табигать көйсезлекләре дә уйландыра. Язын: «Ничек чәчәрбез икән?» – дибез. Яңгыр булмаса, борчылабыз. Быелга да алай ук өметләр юк түгел.

– Авыл нәрсә соң ул синең өчен? – дибез.

– Монда рәхәт. Үз өем, үз җирем, дигәндәй. Шәһәр ыгы-зыгысы, эштән кайткач, машинамны кая куйыйм икән дип уйлыйсы юк *(көлә)*. Мәңге бетмәс «бөке»ләрегез дә юк! Эшләр эшең, торыр җирең булганда, нишләп авылда яшәмәскә соң?! Колхоз җитәкчесе ярдәме белән йорт салып чыктым, хезмәт хакыннан да канәгать мин. Башка чыкканыбызга әле бер ел була гына. Киләчәктә, бәлки, мал-туар да асрап булыр, күз күрер. Зарланып яшәрлек бер генә сәбәп тә юк авылда. Әти-әни дә авылда калуыма сөенгәндер.

> Бәрәскә авылында **355** хуҗалык исәпләнә. Кеше саны – **800**ләп. Мәктәпкә **75** бала йөри, балалар бакчасына – 30лап. Хуҗалыкларда **492** мөгезле эре терлек исәпләнә. Шуларның **273**е – сыерлар.

Басуда узган гомер

Кәримулла ага Әскәровның бөтен тормышы җиргә бәйле. Аның тәмен дә, кадерен дә яхшы белә, кыр тузанын да күп иснәгән, туфрак катысын да күп татыган ул. Россиянең атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы исеме дә юкка гына бирелмәгән бит инде аңа. «Гомерем буе чылбырлы тракторда эшләдем. Эш стажым – 42 ел», – ди Кәримулла ага.

Тормыш дигәне дә яшьтән үк кыен ашаткан үзенә.

– Әби тәрбиясендә үстек. Әти-әниебез бик иртә китеп барды. Әти сугыштан кайткач үлде. Ул чакта миңа 4 яшь иде. Әни 1961 елда китеп барды, энекәш аннан 40 көнлек булып калды. Гаиләдә өч бала үстек без, – дип үткәннәрен барлый ул.

Армия хезмәтен Казахстанда узган Кәримулла ага. Ике ел хезмәт итеп кайтканнан соң, тракторда эшли башлый. 1970 елда үзе дә башлы-күзле була. Хатыны белән 51 ел торалар икән инде. Балаларын да тракторлан ерак җибәрмәгән, техниканы белеп үсәләр. Кызлары хәзер Арчада үз тормышы белән яши. Уллары авылдан ерак китмәгән. Җәмгысы 7 оныклары бар бәхетле Әскәровларның. Өлкән оныкларының никахларын көтәләр. Оныклары да чәчү эшләрендә булышып үсә, кыр хезмәтенең ни икәнен беләләр.

Эшләгән дәвердәге кыенлыкларны исә яшьлек онытгырган, ди Кәримулла ага. «Сизелмәгән дә, эшләдек тә эшләдек инде без. «Юк» дип әйтә дә белмәдем. Авыл җирендә колхоз эше генә түгел бит әле ул. Төнлә колхоз эшеннән кайтасың да башка хезмәткә алынасың. Кеше шикелле генә эшләмәгәндер дә инде. «Трактор ватылды», – дип кенә эшкә чыкмый калулар юк. Ватылган икән, төне буе төзәтәсең дә чыгып китәсең. Хәзерге тормышыбыздан канәгать без. Шушы яшькә җиткәнбез икән, ничек канәгать булмыйсың ди?! 74 нче яшь белән барабыз бит. Бергә укыганнарның күпмесе пенсия яшенә дә җитә алмады...» – дип уйлана ул.

Авылларының хәзерге торышына да канәгать алар, һәр сүз саен шөкер итеп торалар.

– Башка авылларны да күрәбез бит. Күпчелегендә колхозлар юк. Эш булмагач, кешесе дә юк, шунысы борчый, – ди Кәримулла ага. – Илгизебез дә бит әнә, кешегә эш кирәк, эш булсын, дип тырыша. Менә шундый җитәкче кирәк ул бар җиргә дә. Кеше өчен дип эшләгән, кешене кайгырта торган.

Яшьләр тегенди-мондый дип аһ-ух килер урынга, авыл агае, киресенчә, аларны мактый. «Безнең чорда да тәрләләре булгандыр. Кибет юлын үз иткәннәре, башкасы... Ә хәзерге яшьләр бүтән. Тырышлар. Мавыгулары, шөгыльләре бар. Эш яратсыннар, иң мөһиме шул», – ди Кәримулла ага.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

17 июнь сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан Гарифуллина** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Лилия Гыймазова

Автобус булырмы?

Мин – I группа инвалид. Колясклада йөрим. Базарлы Матактан Әлмәткә автобус рейсы ачып булмасмы икән? Анда әниемнең туганнары яши. Барып йөрергә кыен, автобус та, такси да юк. Бер автобустан икенчесенә күчеп барып була булуын, тик бик кыен бит.

Илсөяр ШӘЯХМӘТОВА.
Әлки районы Базарлы Матак авылы

Әлки районы Башкарма комитеты җитәкчесе Илнур Йосыпов җавап бирә:

– Без бу мәсьәләдән хәбәрдар. Хәзерге вакытта әлеге рейсны оештыруның ни дәрәҗәдә чыгымлы булуы тикшерелә. Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына маршрут ачу өчен гариза җибәрдек. Уңай җавап килсә, Базарлы Матактан Әлмәткә кадәр автобус рейсы ачу ихтималы бар.

Сыйфатын кем тикшерә?

Базарларда сатыла торган ит, сөт ризыкларын тикшерүче бармы соң ул? Итләрнең сулары агып тора бит. Элек алай булмый иде. Мин һәр шимбә саен Дәрвишләр бистәсендәге базарга йөрим, андагы ит тә шундый. Ә сөтләре сыек, кайсы елганың суын гына кушмыйлардыр аңа. Бераз тикшерсеннәр иде.

Фәрит ГАЛИЕВ.
Биектау

Казан шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсенең ветеринария-санитария экспертизасы бүлеге башлыгы Валентина Рысаева җавап бирә:

– Дәрвишләр бистәсендә төгәл кайсы базар икәне билгеле булса, җавап та төгәлрәк булыр иде.

Казанда барлыгы 10 ветеринария лабораториясе, 11 ветеринария контроле пункты (рөхсәт документларын тикшерү буенча) эшли. Дәрвишләр бистәсендә ветеринария-санитария экспертизасы базарлар эчендә сатучыларның гына итсөт, балык, яшелчә, умартачылык продукциясенә ясала. Базар тирәсендә аерым сатучыларның товарын ветеринария табиблары тикшерми. Болары – рөхсәтсез сатучылар. Мәсәлән, «Универсам» тукталышындагы «ИП Алексеев» базары эчендәге территориядә барлык ит-сөт продукциясе тикшерү уза, яшелчә, җиләк-җимешләрдәге радиация һәм нитратлар күләме тикшерелә. Базарда сатучыларда бер сату көненә генә бирелә торган рөхсәт документы була. Әлеге документта рөхсәт биргән ветеринария берләшмәсенең адресы язылган һәм табибының исемле мөһере куела. Сатып алучылар ит-сөт сатучылардан шушы документны курыкмыйча сорый ала, һәм сорасыннар да иде.

Базар читендә мөстәкыйль рәвештә сатучыларның продуктлары тикшерелми, аларның сатуга рөхсәте юк. Алар саткан продукциянең сыйфаты өчен ветеринария табиблары җавап бирми. Шимбә көнне эшли торган чатырлы базарда ветеринария табиблары продукцияне шимбә көнне генә тикшереп чыгара.

Кибетләргә килгәндә, «Метро», «Ашан», «Лента» кебек зур кибетләр челтәрләре киштәләренә ит-сөт, яшелчә, балык продукциясе ветеринария контроле аша үтеп, рөхсәт документлары тикшерелеп кертелә. Кечкенә кибетләрдә дәүләт ветеринария табиблары хезмәт күрсәтми.

Фатир кайчан булыр?

Алена Панарина исемле ятим кыз исеменнән бирәм бу соравымны. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, торак белән тәэмин ителергә тиешле балалар исемлегенә фатир алырга чиратка баскан иде. Аңа фатир кайчан булыр икән? Белешә алмассызмы?

ИЛНАЗ.
Балык Бистәсе

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Алсу Мөхәммәтова җавап бирә:

– Панарина Алёна Васильевна ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, торак белән тәэмин ителергә тиешле балалар исемлегенә керү өчен 2018 елда гариза белән мөрәҗәгать итте. Ләкин аның гаризасы кабул ителмәде, чөнки ул берәүнең дә исеменә рәсмиләштерелмәгән һәм торак нормасыннан зуррак мәйданлы фатирда теркәлгән булып санала. Бу мәсьәләдән чыгу юллары икәү. Әгәр аңа хәзерге вакытта теркәлеп яши торган фатиры кирәкми икән, ул судка гариза биреп, аны дәүләт карамагына күчерә ала. Шул очракта кыз алда әйтелгән исемлеккә кертеләчәк. Икенче юл – кыз үзе теркәлгән фатирны суд карары белән үз милке итеп рәсмиләштерә ала.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Фикер

Ниһаять, безне дә зурлый башладылар. 2 майда ураза гаетеннән соң авылның имам-хатыйбы Илшат Мирфаяз улы авылдашларга, теләгән кешеләр мәктәп ашханәсенә аш мәҗлесенә килә ала, дип белдерү ясады. Бу «Башак» хуҗалыгының элеккеге җитәкчесе Хәлил Мансур улының авыл халкын хөрмәтләве булгандыр. Ә хуҗалыкның хәзерге җитәкчесе Илүс Ярмиев сугыш чоры балаларына 9 Май көнне күчтәнәч таратты. Күчтәнәч пакетында нинди генә тәм-том юк иде!

Аллага шөкер, хәзер ачлык чоры түгел, ашарга – ризыгыбыз, кияргә киемебез бар. Тик безнең ачлы-туклы, ярымшәрә килеш җиңүне якынайтуыбызны күрмәмешкә салышулары, әһәмият бирмәүләре генә борчый. Үземнең яшьтәшләремә шуны әйтәсем килә: безне искә алмасалар да, нык булдык, бернинди авырлыкларга бирешмәдек. Калган гомерне дә шулай сау-сәламәт булып яшәргә язсын!

85 яшьлек бабагыз Гатуф БӘДРӘШИТОВ.
Актаныш районы Яңа Әлем авылы

Укучы сүзе

ФИРАЯ ӘКБӘРОВА: «КАРТАЙМЫШ КӨНЕМДӘ ЧӘЧӘК АТТЫМ»

Фирая ханым, сез шундый көләч, ягымлы, тик нигәдер «карточкагызны бозасыгыз килсә, минем белән төшегез» дигәнсез. Ике егет тәрбияләп үстергән хатын-кыз берничек тә ямьсез була алмый. Сезгә, горурланып, дөньяда иң матуры мин, дип яшәргә кирәк алдагы көннәрдә. Сезгә сәламәтлек, бәхетле, бәрәкәтле гомер, иҗади уңышлар телим. Тамашачыларыгызны сөендерергә насыйп итсен Аллакаем.

М. ЛАЗАРЕВА

ҖИР КЕМГӘ КИРӘК?

Авыл кешесе белән шәһәр кешесе хәтта ярминкәләрдә дә аерыла. Шәһәр кешесенә очсызга ит, сөт, май, йомырка, яшелчә кирәк. Авыл кешесенә дә арзанрак бәягә көрәге, сәнәге, чиләге, киеме һәм башкасы кирәк. Ләкин шәһәрдән авылга ярминкәгә килгәннәрен ишеткәнем юк.

Раушания ЯППАРОВА

* * *

Нәкъ минем әйтәсе килгән фикерне язгансыз. Мин гел шулай дим. Дөрес бит. Яз көне бакча эшләре башланыр алдыннан авылларга чыгып, очсызрак бәягә көрәк, сәнәк, чиләк, тырма, гомумән, авыл тормышы өчен кирәк-яраклар сатмыйлар. Ә үзләренең очсыз бәягә ит, сөт, йомырка, яшелчә ашыйсылары килә.

Сиринә ХӨСНЕТДИНОВА

* * *

Шәһәр кешесенең дә сменалап эшләгәне авыл кешесеннән азрак эшләми. Өчәр сменалыларының күбесенең балалары үзләре генә куна, барысының да әбиләре янәрында яшәми. Барысы да түрә түгел, шулай булгач, авыл, шәһәр дип аерырга кирәкми.

СИРИН

ВТ

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:

I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.

Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:

«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

13 июнь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН
21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
06.30 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.30 «Өметеңне өзмә». Рифат Зарипов концерты 6+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.30 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.30 «Җиде малай». Фирдүс Тямаев концерты 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Танцы народов мира» 6+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
19.00, 20.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Здоровая семья» 6+
00.35 «Если хочешь быть здоровым» 12+
00.50 «Не от мира сего...» 12+
02.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Җанымда яз булып кал әле». Эльмира Җәлилованың иҗат кичәсе 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00 «Ватандашлар» 6+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Мирсәй Әмир турында телеочерк 6+
13.00 «80 яшьлек егет». Татарстанның халык артисты Наил Дунаевның юбилей кичәсе 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Гармунчы». Татарстанның атказанган артисты Наил Сәгъдиевнең иҗат кичәсе 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
06.00 Новости
06.10 «Россия от края до края» 12+
06.30 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ») (S) 16+
08.20 Фильм «ПОЛОСАТЫЙ РЕЙС» 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «КАК РАЗВЕСТИ ДЖОННИ ДЕППА» 16+
11.20 Даниил Страхов. «ЗНАХАРЬ» (S) 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Знахарь» (S) 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Знахарь» (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «Знахарь» (S) 16+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» Летняя серия игр. Финал (S) 16+
23.55 «Леонид Кравчук. Повесть о щиром коммунисте» 16+
00.50 «Наедине со всеми» 16+

РОССИЯ 1
05.35 Елена Яковлева, Валерий Афанасьев, Алёна Яковлева, Владимир Стержаков, Елена Захарова, Александр Макогон. «ЛЮБОВЬ НЕЖДАННАЯ НАГРЯНЕТ» 12+
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 15.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.05, 15.15 «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу. Специальный праздничный выпуск 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Премьера. «НЕБО» 12+
00.00 «БАЛКАНСКИЙ РУБЕЖ» 16+
02.45 «ОХОТА НА ПИРАНЬЮ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 Профессиональный бокс. Бой за титул чемпиона России в лёгком весе. Трансляция из Сочи 16+
07.00, 09.05, 12.35, 14.55, 16.50, 19.50 Новости
07.05, 19.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 «СПОРТ ТОША». Мультсериал 0+
09.30 Футбол. Лига Европы. «Рубин» (Россия) – «Челси» (Англия) 0+
11.30, 12.40 «ФАРТОВЫЙ» 16+
13.30, 15.00 «РОК-Н-РОЛЬЩИК» 16+
15.45 «Громко». Прямой эфир
16.55 «Неделя лёгкой атлетики». Прямая трансляция из Москвы
18.30 Матч! Парад 0+
19.55 Пляжный волейбол. BetBoom Чемпионат России. Финал. Прямая трансляция из Анапы
22.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.45 Бокс. Bare Knuckle FC. Трансляция из США 16+
01.50 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Атланта Стим» – «Чикаго Блисс» 16+
02.40 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
03.05 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.30 Новости 0+
03.35 «Где рождаются чемпионы. Наталья Ищенко» 12+
04.00 «Неделя лёгкой атлетики». Трансляция из Москвы 0+
05.05 «Громко» 12+

НТВ
05.30 «Морские дьяволы. Смерч. Стихия героев» (S) 16+
06.10, 08.20, 10.20 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
13.10 «ПОСЛЕДНИЙ ГЕРОЙ» (S) 16+
15.00 «ЧЁРНЫЙ ПЁС» (S) 12+
16.20 Остросюжетный фильм «ЧЁРНЫЙ ПЁС» (S) 12+
19.40 «ЧЁРНЫЙ ПЁС-2» (S) 16+
23.40 «Прорыв». Фестиваль экстремальных видов спорта (S) 0+
01.05 «КТО Я?» (S) 16+
02.45 «Таинственная Россия» 16+
03.25 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «ОСТРОВА» 16+
08.30 «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» 16+
10.45 «СКОЛЬКО ЖИВЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
14.55 «В ОТРАЖЕНИИ ТЕБЯ» 16+
19.00 «ПОГОВОРИ С НЕЙ» 16+
22.45 «ТРИ ДНЯ НА ЛЮБОВЬ» 16+
00.35 «АНЖЕЛИКА И КОРОЛЬ» 16+
02.15 «НЕУКРОТИМАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
03.40 «АНЖЕЛИКА И СУЛТАН» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.40 «Лаборатория любви» 16+

ЗВЕЗДА
06.00 «СЕМЕН ДЕЖНЕВ» 12+
07.15 «ЦЕЛЬ ВИЖУ» 16+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
10.30 «Военная приемка» 12+
11.20 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №104». Премьера! 16+
12.05 «Секретные материалы». Документальный сериал. «Сталинград в огне. Первый удар» 16+
12.50 «Код доступа». «Рубль. Легко ли быть золотым?» 12+
13.35 «Легенды госбезопасности. Яков Серебрянский. Охота за генералом Кутеповым». Документальный фильм 16+
14.20 «ДОРОГАЯ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
20.00 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу. Премьера! 12+
23.45 «СВАДЬБА С ПРИДАНЫМ» 12+
01.30 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ» 16+
02.55 «Александр Третий. Сильный, державный...» Док. фильм 12+
03.50 «ДОРОГАЯ». 1-я и 2-я серии 16+

14 июнь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
06.30, 07.10, 08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Османие. На пути к вере 12+
00.40 «Здоровая семья» 6+
00.55 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.10 «Уроки истории». Татарстан и татары 6+
02.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Казанның кадерле кичләре». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиева концерты 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30,20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Гомәр Бәширов турында телеочерк 6+
13.00 «Кайда сез, яшьлек елларым?» Зөһрә Шәрифуллина концерты 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Казан» бию ансамбле концерты 6+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Виктория Исакова. «ЗАКЛЮЧЕНИЕ» (S) 16+
23.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «БЛАГОСЛОВИТЕ ЖЕНЩИНУ» 12+
03.10 «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 09.05, 12.35, 14.55, 16.50 Новости
06.05, 18.00, 20.00, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Спец. репортаж 12+
09.30 Футбол. Лига чемпионов. «Манчестер Сити» (Англия) – ЦСКА (Россия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ЗАСТЫВШИЕ ДЕПЕШИ» 16+
15.55, 16.55 «ФАРТОВЫЙ» 16+
18.30 Смешанные единоборства. Прямая трансляция из Ульяновска
20.30 Хоккей. 3х3. Чемпионат ФХР. Кубок «Лиги Ставок». Прямая трансляция
23.45 «Есть тема!» 12+
00.05 «ЭКСТРЕМАЛЫ» 12+
01.50 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Сиэтл Мист» – «Остин Акустик» 16+
02.40 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
03.05 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.30 Новости 0+
03.35 Автоспорт. Фестиваль Суперкаров UNLIM 5 0+0+
04.00 Легкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция из Финляндии 0+

НТВ
05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.05 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Евгений Дятлов. «АКУЛА» (S) 16+
23.25 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
03.05 «Их нравы» 0+
03.20 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Бездетный» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ПЯТЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
19.00 «У КАЖДОГО СВОЯ ЛОЖЬ». 1-я – 4-я серии 16+
22.55 «Порча» 16+
23.25 «Знахарка» 16+
23.55 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.10 «Тест на отцовство» 16+
02.50 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.20 «ДОРОГАЯ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30, 13.25, 03.50 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
09.50 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
11.20, 18.50 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.35, 14.05 «Легенды госбезопасности. Сергей Федосеев. Судьба контрразведчика». Док. фильм 16+
14.00 Военные новости 16+
14.30 «ПОКУШЕНИЕ». 1-я – 4-я серии 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
20.50 Новости дня 16+
21.50 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.15 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
23.05 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Александр Федотов. Премьера! 12+
23.55 «ДВА КАПИТАНА» 12+
02.20 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ-2» 16+
04.00 «ПОКУШЕНИЕ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ
13–19 ИЮНЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Кесә ягын калынайту турында уйлау өчен бик уңайлы чор. Уйлау гына түгел, бу юнәлештә әйбәт кенә адымнар да ясалыр.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Божрадагы тиен кебек һаман бөтерелеп торсагыз да, кайбер эшләргә өлгермәссез. Хафаланасы юк: озакламый ярдәм кулын сузучылар пәйда булыр.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Кешеләр белән аралашуда кайбер кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин. Әйтик, абруегызга зыян салырдай бер эшкә тартып кертүләре бар. Шуңа күрә әйткән бер сүзгә ышанмагыз.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Атна башында шәхси ирекнең кесә калынлыгына бәйле булуын аеруча нык сизәрсез. Борчыласы юк: акча кытлыгы бик тиздән хәл ителәчәк. Әйбәт кенә премия һәм читтән дә шактый ук керем көтелә чөнки.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Күчемсез милеккә бәйле документлар рәсмиләштерү өчен бик уңайлы чор. Бу эшне сез бернинди тоткарлыксыз, бюрократик киртәләрсез башкарып чыгачаксыз.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Бу атнада сөеклегез белән «без», «бергә» дигән сүзләрне ешрак кулланып сөйләшегез әле: үзара аңлашуга дөрес юл әнә шулай ачылачак. Хезмәттәшегездән ишетелгән бер хәбәр күңелегезне күтәреп җибәрәчәк.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Атна башында дулкынландыргыч хәлләр булып алыр. Аның каравы матди хәлегез яхшырыр. Эштә күпләрне көнләштерерлек уңышларга ирешүдә өйдәге татулык-тынычлык һәм үзара аңлашу да зур өлеш кертер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Атна башында шәп кенә сюрприз булачак. Бу, күңелегезне үсендереп, гомумән, үзегезне бер башка үстереп җибәрәчәк. Атна ахырына корып куелган планнарыгыз искиткеч дәрәҗәдә җиңел һәм нәтиҗәле килеп чыгачак.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Бу атнада бер мәлгә туктап калып, уйларга бирелеп алырга кирәк булыр. Чыннан да, кирәклене, күңелем теләгәнне эшлимме соң мин, дигән сорауга җавап табу өчен. Танышыгызның уйнап кына әйткән сүзләре, ни гаҗәп, чуалган фикерләрегезне тәртипкә салырга ярдәм итәр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Дусларыгыз белән мөнәсәбәтләр какшабрак китмәгәе. Сәбәбеме? Вәгъдә ителгәнне эшләмәү. Хуш, ниятләнелгәннәрне аларның ярдәменнән башка да башкарып чыгачаксыз. Әле ничек кенә!

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Умарта корты кебек, бертуктаусыз эшләвегез һәм әйбәт кенә уңышларга да ирешүегез кемнәрнеңдер ачуын чыгарыр. Көнчелектән шартларга җитешеп йөрүчеләрне күрмәмешкә, ишетмәмешкә салышыгыз. Шулай икән, алар игътибарын башкаларга күчерергә мәҗбүр булыр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Сөеклегез белән үзара әйткәләшеп алулар ешаер. Бер-берегезгә юл куймыйсыз чөнки. Тәнкыйтьләүдән туктагыз әле – дөньягыз шундук тынычланып, яктырып китәр.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ КАРАР

08.06.2022 Казан ш. №539

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Россия чемпионатын үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 23.04.2009 ел, №256 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Россия чемпионатын үткәргәндә кешеләрнең иминлеген тәэмин итү максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Билгеләргә:

Казансу елгасында, Кремль дамбасыннан «Миллениум» күперенә кадәрге өлешендә, кечкенә суднолардан, ял судноларыннан, спорт-җилкәнле суднолардан файдалануны тыюны:

2022 елның 17 июнендә 09.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә,

2022 елның 18 июнендә 05.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькәчә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән суднолардан файдалануны тыюның Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Россия чемпионатына әзерләнү һәм аны үткәрүгә җәлеп ителгән судноларга кагылмавын.

2. Татарстан Республикасы Гражданлык оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

бу карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатыннан, күрсәтелгән участокларда көч һәм средстволарның дежур торуын тәэмин итәргә;

халыкка, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша, кертелә торган тыю турында мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләренең аянычлы нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә, бу карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатыннан, көч һәм средстволарның дежур торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В. Песошин

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

НАРКОЗ ГОМЕРНЕ КЫСКАРТМЫЙ

Берәүләр аны гомерне кыскарта дип саный. Икенче берәүләр аңа сызлау-авыртуларны сиздермәгәне, кайчак хәтта гомерне саклап калганы өчен рәхмәтле. Сүзебез анестезия (наркоз) турында. Аңа ничек әзерләнергә? Анестезия гомерне кыскарта диюләре дөресме? Кеше операция вакытында уяна аламы?

Башкаланың 16 номерлы шәһәр клиник хастаханәсенең анестезиология һәм реанимация бүлеге мөдире, анестезиолог-реаниматолог Владислав БОЙКОВ сорауларга ачыклык кертте.

:: Владислав Владимирович, күпләрне кызыксындырган сораудан башлыйк әле. Наркоз гомерне уртача ун елга кыскарта, диләр. Бу дөрестән дә шулаймы?

– Бу – уйдырма. Бүген анестезия вакытында кулланылган препарат, күзәтү җиһазлары, анестезиологның белеп эш итүе аркасында анестезиянең организмга зыяны юк дәрәҗәсендә. Ул, киресенчә, организмны саклый. Ул гомерне шартлы рәвештә озайта дип әйтсәк тә була. Ник дигәндә, сау-сәламәт кешегә тик торганда операция ясамыйлар бит. Анестезия нәкъ менә кешене нинди дә булса катлаулы чирдән дәвалау, азат итү өчен кулланыла. Шул рәвешле аның гомере, киресенчә, озая дип әйтсәк тә ялгыш булмас.

:: Кеше операция вакытында уяна алмы?

– Анестезия – организмның тышкы ярсыткычларга, авыртуга сизгерлеген киметүгә юнәлтелгән чара. Гомуми анестезия (наркоз) төрле дарулар, җиһазлар ярдәмендә, табиб-анестезиолог контролендә башкарыла. Шушы барлык шартлар да тиешенчә үтәлгән очракта кеше операция вакытында берничек тә уяна алмый.

:: Наркоздан соң кеше күпме вакыт эчендә айный?

– Кешенең анестезиядән никадәр иртә айнуы аның төренә бәйле. Әйтик, катлаулы булмаган операциядән соң кеше якынча 10 минут эчендә уяна.

:: Кайсы очракларда наркоз куллану кискен тыела?

– Бу шулай ук аның төренә бәйле. Гомумиләштереп әйтсәк, йөрәк-кан тамыры, сулыш органнарының катлаулы авырулары вакытында наркоз куллану тыела.

:: Наркоз өчен яшь чикләве бармы?

– Яшь чикләве юк. Аны ясаганда кулланылган препарат составындагы матдәләргә карата гына чикләү була ала.

:: Наркоз вакытында төшләр дә керә, диләр.

– Әйе, наркоз биргән мәлдә кеше төш күрергә мөмкин. Авырулар арасында ачык, төсле төш күрдем дип әйтүчеләр бар. Бу төшләр бик кыска була. Иң кызыгы: алар истә дә кала.

:: Анестезиягә ничек әзерләнергә?

– Аны ясарга алты сәгать кала ашарга ярамый. Наркозга ике сәгать кала су эчү дә тыела.

:: Операциядән соң кайчан ашарга, эчәргә рөхсәт ителә?

– Артык катлаулы булмаган операциядән соң яки кул-аякка операция ясагач, операция бетүгә үк ашарга, эчәргә рөхсәт ителә.

АНЕСТЕЗИЯ ТӨРЛӘРЕ

Төре	Нидән гыйбарәт?	Ничек башкарыла?	Үзенчәлеге
Тынычландыручы (седация)	Аң томалана, авыруның тышкы ярсыткычларга реакциясе чикләнә.	Ул катетер аша кан тамырына кертелә яки анестезия ясый торган маска ярдәмендә башкарыла.	Аның җиңелчә төре кешенең куркуын басар өчен генә башкарыла. Уртача седация вакытында кешенең аңы томалана, әмма ул тышкы тәэсирләрне сизә. Тирән седация вакытында исә авыру каты авырту һәм кабатланып торган ярсыткычларны гына сизә.
Гомуми анестезия	Кеше аңсыз, авыртуны сизми, селкенә алмый.	Катетер аша да, анестезия ясый торган маска ярдәмендә дә башкарыла.	Гомуми анестезиядән айныгач, кеше берничә сәгать дәвамында йокымсырап йөрергә мөмкин. Кайберәүләр күңел болгану, тамак авыртудан да зарлана.
Регинар (өлешчә, аркага ясала торган, эпидураль)	Өлешчә анестезия вакытында гәүдәнең кечкенә генә бер өлеше «туңдырыла», Кеше үз аңында була, әмма авыртуны сизми. Анестезиянең бу төре, гадәттә, теш алдырганда, тирегә кереп үскән тырнакны алдырганда кулланыла. Аркага ясала торган, эпидураль анестезия вакытында тәннең билгеле бер өлеше хәрәкәтсезләндерелә.	Эпидураль анестезия вакытында арка мие нервлары урнашкан урынга дару кертелә. Аркага ясала торган анестезия вакытында арка мие сыеклыгына дару салына.	Аны ясаганда кулланылган препаратларга аллергия булганда, укол ясалачак урында тән тиресе ялкынсынса, каны сыек, түбән кан басымыннан интеккән кешеләргә ясау тыела.

Сорау – җавап

Маймыл чәчәге куркыта...

Маймыл чәчәк авыруы Россиягә якынлаша. Белгечләр шулай дип чаң суга. Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова бу авыруның безгә керү куркынычын кире какмый. «Шул ук вакытта куркыныч алай ук зур да түгел», – ди ул.

НИЧЕК ТАРАЛА? Маймыл чәчәк авыруы – кешегә кимерүчеләр һәм приматлар аша йога торган сирәк вируслы авыру. Вирус организмга зарарланган тән тиресе, тын юллары, күзнең, борынның лайлалы тышчасы аша йогарга мөмкин. Шулай ук маймыл чәчәк авыруы вируслы хайваннардан (маймыллар, күселәр, тиеннәр), урын-җир аша йога.

НИЧЕК УЗА? Ул гадәттә җиңел формада үтә. Авыруның беренче билгеләре – югары тән температурасы, баш, арка, мускуллар авырту һәм хәлсезлек. Бизгәк кимүгә таба тәнгә кычыта торган тимгелләр чыга, башта биттә, соңыннан тәннең башка өлешләренә, шул исәптән аяккулларга тарала. Ахырда тимгелләр кутырлый, кутырлар коела, сирәк очракларда тимгелләр урынында эзләр кала. Чир 2–3 атна дәвам итә һәм еш кына үзеннән-үзе үтә.

БАНАН САТЫП АЛУ КУРКЫНЫЧМЫ? Юк, куркыныч түгел. Маймыл чәчәк авыруы таралганнан бирле бу чирне җиләк-җимеш, аерым алганда, банан аша йогыту очраклары теркәлмәгән. Ник дигәндә, вирус таралсын өчен дымлылык, температура кебек билгеле бер шартлар кирәк. Өстәвенә барлык яшелчә, җиләк-җимешләр, озаграк саклансын өчен, махсус эшкәртелә. Шуңа күрә алар аша бернинди чир дә йога алмый.

ВАКЦИНА БУЛЫШАМЫ? Гадәти чәчәк чиренә каршы вакцина маймыл чәчәк чирен булдырмауда 85 процентка нәтиҗәле, ди белгечләр. Әмма чәчәк чире вирусы югалганнан соң аңа каршы прививка ясату тукталды. Шуңа да маймыл чәчәк чире таралуына киртәләр юк.

Файдалы

ЧИКЛӘВЕКНЕҢ МЕҢ ШИФАСЫ

▶ Әстерхан чикләвеге А, B_1, B_2, Е, РР, С витаминнарына, клетчатка, тимер, кобальт, цинк, калий, магний, кальций, йод, фосфорга бай. Ул йокысызлык, гельминтоз, дерматит, нерв тайпылышлары, йөрәк чирләре, гипертония, авитаминоз, азканлылыктан ярдәм итә. Бавырны чистарта, иммунитетны ныгыта, кабыгы тире авыруларын дәвалау өчен кулланыла.

▶ Урман чикләвеге (фундук) сахароза, каротин, тимер, цинк, B_1, B_2, С, Е, РР витаминнарына, аксымга бай. Эчәк авырулары, азканлылык, авитаминоз, рахит, колит, бөердә таш булганда ярдәм итә. Бала белән ашаганда бала имезүче хатынның сөтен арттыра. Анда матдәләр алмашын яхшыртучы, организмда картаю процессларын акрынайта торган майлар бар.

▶ Пестә чикләвеге (фисташка) яшелрәк булган саен сыйфатлырак. Ул А, B_1, Е витаминнарына, тимергә бай. Тонусны күтәрә, организмны ныгыта, йөрәк тибешен җайга сала, баш мие, бавыр эшчәнлегенә уңай йогынты ясый, көч кертә, канны чистарта, ир-атның җенси куәтен арттыра.

▶ Бадәм (миндаль) В һәм Е витаминнары, аксым, тимер, цинк, кальций, магний, фосфорга бай. Холестеринны киметә, гипертония, симерү, ашказаны җәрәхәте, сару кайнаудан файдалы.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

БАКЧАНЫҢ «КЫЗГАН» ЧАГЫ

ҖӘЙНЕҢ БЕРЕНЧЕ АЕНДА БАКЧАДА НИНДИ ЭШЛӘРНЕ БАШКАРЫП КАЛЫРГА?

Россельхозцентр филиалының җитәкче урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВА киңәшләре

Сибәргә, сирәкләргә

Бакчада беренче чиратта башкарылырга тиешле эшләр хакында онытмагыз. Болар:

✓ кышка саклау өчен чөгендер утыртыргa, ә май аенда утыртылганын арасын 5 см калдырып сирәкләргә;

✓ кәбестәнең соң өлгерә торган сортлары үсентеләрен утыртырга;

✓ кабат ике атна аралыгы белән тиз өлгерешле – шпинат, салат, редис орлыкларын чәчәргә;

✓ чүп үләннәрне утарга һәм куерып киткән үсентеләрне сирәкләргә.

Агачлар да авырый

Крыжовник, кура җиләге куакларының очларын кисәргә өлгермәгән булсагыз, хәзер аның өчен кулай вакыт. Бөре талпаны (почковый клещ) белән зарарланган карлыган ботакларын кисәргә, әгәр куак бик нык зыян күргән булса, бөтенләй кисеп яндырырга кирәк.

Җәйнең беренче аенда җимеш бирүче агач куакларын тукландыру турында да онытмагыз. Җимешләре күренә башлауга төбендәге катнашманы ясап сибәргә кирәк. Моның өчен тиресле су (1:2), сыер тизәге (1:8–10), аммиак селитрасы (25–30 г), мочевина (20–25 г/ м²) кирәк булачак. Әлеге катнашманы һәр карлыган төбенә 10 литр, ә кураның һәр метрына 5 л сибеп чыгарга киңәш ителә.

Июньдә алма белән грушаны – кутырдан (парша), ә крыжовникны онсыл чыктан (мучнистая роса) саклау чарасын күрәбез. Агач-куакларны карап, пәрәвез ояларын, бөтәрләнгән яфракларны, бөҗәк йомыркаларын алып ташлыйбыз. Гөмбә авыруларыннан саклау өчен биологик фунгицидлар («Псевдобактерин-2», «Ризоплан», «Фитоспорин М»), төрле авырулардан саклаучы микроашламалар («Гумат+7», «Здоровый урожай»), микробиоашламалар («УниФос», «Азолен») куллану да файдага булыр.

Гөлнара Зиннәтуллина

Аючикерткәгә – капкын

Җәй башында бакчаларда аючикерткәләр (медведка) активлаша. Аны тоту өчен җиргә такталар куярга мөмкин, алар кичен шунда җыелачаклар. Аючикерткәне тоту өчен бал белән капкын ясарга була. Моның өчен пыяла банканың каплый торган өлешенә эчке яктан бал сөртеп, «тамагы»на кадәр балчыкка күмәргә. Банка авызын 1–1,5 см тишек калдырып, такта кисәге белән капларга. Балга алданып, капкынга төшкән корткыч бөҗәк аннан чыга алмаячак.

Сабын белән көл файдалы

Бакчадагы яшелчә, җиләк-җимешләрне күп төрле корткыч бөҗәкләрдән саклау өчен көл белән кер сабыны кушып ясалган катнашма сибәргә мөмкин. Кырмыскалардан котылу өчен аларның ояларына кайнап торган су салсагыз була.

Гөбләә – үлән бетләреннән котылу өчен үлән, тәмәке, сабын белән көл салып ясалган катнашмалар һәм «Фитоверм», «Биостоп» препаратлары кулланыгыз.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

Исеңдә тот!

БАЛЫК ТАРАЛЫП КИТМӘСЕН

Йомшаграк балык табада кыздырганда таралып китә һәм алтынсу төскә дә керми. Болай килеп чыкмасын өчен, әзерләргә 10–15 минут кала аны кәгазь сөлге белән корытып сөртергә һәм шундук тоз сибәргә кирәк. Ә инде балык кисәкләрен әвәләү өчен онга вакланган чикләвек өстәргә мөмкин. Тышчасы телеңне йотарлык булачак!

Тәмле кәтлит

Ит яки балык кәтлитен дөгедә әвәләп әзерләү ысулын беләсезме?! Ярманы каһвә тарткычта ваклап, шуңа уылган сыр өстәгез. Кәтлитләр искиткеч тәмле булып пешәчәк.

ЯШЕЛЧӘ БОЗЫЛМЫЙ

Суыткычның яшелчә тартмалары төбенә кәгазь «сөлге» җәеп калдырырга кирәк. Ул, дымны үзенә сеңдереп, яшелчәне озаграк саклау мөмкинлеге бирәчәк.

Тәмле булсын!

Чәкчәк сере

Кукмара районының Адай авылында гына түгел, күрше төбәкләрдән дә килеп, Илсөяр апа Галимяновадан чәкчәк пешертәләр икән. Гомере буе фермада эшләгән ханымның авылда аш-суга осталыгы турында даны таралган була инде. Шуңа да аны, пенсиягә чыгуга, пекарняга чакырып алалар. 66 яшенә кадәр шунда эшли.

– Бервакыт кунакка баргач, шундый тәмле чәкчәк ашадык. Аны килендәшем Гөлзада пешергән иде. Барыбызга да рецептын язып таратты. Кайттык та оныттык. Әмма бераз вакыт узгач, мин пешереп карарга булдым. Балаларым да ошатты. Кучтәнәчкә дә күп бирдем. Тәмле булгач, яраттылар. Хәзер инде кешедән килгән заказлар шулкадәр күп, – ди Илсөяр апа.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ИЛСӨЯР АПАДАН ЧӘКЧӘК РЕЦЕПТЫ

Туңдырылган 10 йомырканы миксер белән яхшылап болгатабыз. Шуңа он өстибез. Онны кашыктан купканчы бутарга кирәк. Аннары катнашманы кунага төшерәбез дә, табак каплап, 10 минут ял иттерәбез. Шуннан соң токмач камыры кебек итеп җәябез дә, камырны тагын 10 минут ял иттерәбез. Аннары эре токмач төсле кисеп пешерәбез. Чәкчәкне газ өстендә түгел, мичендә пешерәбез. Әмма табадагы майны әз генә җылытып алырга кирәк.

Чәкчәкләрне балга катыру өчен катнашма болай ясала: 0,5 килограмм шикәр комына 0,5 килограмм бал салына. Шуңа ике кашык су өстисе. Катнашма күбекләнгәч, төшләрне бутыйсың да куңелең теләгәнчә бизисең.

Үзем сынадым

«КАРБЫЗ СУ ЯРАТМЫЙ»

Баулы районының Исергәп авылында яшәүче Нәсимә апа Фәйзуллина бакчасында утыз елдан артык кавын, карбыз үстерә. Зурлыгына кызыкмый, бакчачы өчен тәме мөһим. Иң зур дигән кавын-карбызлары – 3–4 килолы.

– Орлыкларны бер атна элек чәчтем, тишелеп чыкты инде. Ачык грунтка утыртам, өстен капламыйм. Араларын 1,5 метр калдырып, ун метрлы бураэналар сызам. Бер юлга – бер, икенчесенә икенче төрле сортлар утыртам. Бакчада буш урын калдырмаска тырышам. Аның каравы җимешен рәхәтләнеп ашыйм. Июль аенда беренче кавыннардан авыз итә башлыйм инде. Узган ел уңышы бик шәп булды. Балаларга да кучтәнәчкә биреп җибәрәм. Авылдашларны да сыйлыйм. Орлыгын сораучылар да бар, тик үстерүчеләр күренми, – ди авылда хат ташучы булып эшләүче 70 яшьлек Нәсимә апа.

Ташкентта яшәгәндә, әтисе гел кавын-карбыз утырта торган булган икән. 1994 елда Нәсимә апа туган авылына күченеп кайткан. Менә шуннан бирле көньяк җимешләрен үз бакчасында үстерә. Эре сортларын да утыртып караган, тик алары балланып өлгерми икән. Шуңа күрә ваграк уңыш бирә торганын сайлый. Нәсимә апа әйтүенчә, кавын-карбыз үстерүнең берниди авырлыгы да юк. Моның өчен көннәрнең җылы булуы һәм теләк кенә кирәк. Су сибәргә дә кирәкми, яңгыр дымы да җитә, ди. Су сипкәч, киресенчә, чәчәкләре каралып киткән. Җире яхшы булсын өчен көл сибә, тирес белән ашланган урынга утырта. Бары шул гына. Безгә көйсез кебек тоелган карбыз, кавын артык мәшәкать сорамый икән бит.

Сәрия МИФТАХОВА

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

МӨЛКӘТ БЕТӘР, ТӘРБИЯ КАЛЫР

Бала багу савaплы, диләр. Бу – олы әманәт. Коръән аятьләрендә дә, пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрендә дә ата-ананың бала тәрбияләүгә кагылышлы вазыйфалары күрсәтелгән. Тик яше барган саен, баланың характеры да, үз-үзен тотышы да үзгәрә. Көйсез чакта бәгырь җимеше белән мөнәсәбәтне ничек көйләргә? «Күчеш чоры»н ничек үтәргә? Бала тәрбияләгәндә нәрсәләрне истә тотарга?

Бу һәм башка сорауларга Наил хәзрәт ЙОСЫПОВ белән җавап эзләдек.

:: Пәйгамбәребезнең (с.г.в) балаларга карата мөнәсәбәте бик күркәм булуы билгеле. Моны раслый торган нинди хәдисләр бар?

– Сөекле пәйгамбәребезнең (с.г.в.) балаларны яратуы, аларга ягымлы мөнәсәбәттә булуы, вакыт-вакыт алар белән уйнавы, шаяруы хакында бик күп истәлекләр бар.

Балачагында әнисе рәсүлебез (с.г.в.) янына йомышчы итеп китергән Әнәс бине Мәлик (р.г.) шундый риваять әйтеп калдырган: «Мин Аллаһның рәсүле (с.г.в.) янында ун ел хезмәт иттем. Ул миңа бер тапкыр да уфтанмады. «Моны нигә болай эшләдең? Ә моны нигә эшләмәдең?» – дип әйтмәде. Ул кешеләрнең иң күркәм холыклысы иде. Көннәрнең берсендә мине бер урынга йомыш белән җибәрде. Аның әмерен үтәр өчен тышка чыктым. Урамда уйнаган балаларны күргәч, аларга кушылып онытылып киткәнмен. Бераздан артымнан Аллаһның рәсүле (с.г.в.) килде һәм мөбарәк йөзендә елмаю булган хәлдә: «Йә Әнәс! Мин кушкан җиргә бардыңмы?» – дип сорады. Мин исә: «Әйе, менә китеп барам, йә Рәсүлуллааһ», – дидем. Үзенең оныкларын гына түгел, башка балаларны да ихлас күңелдән яратты, аларга башлап сәлам бирде. Сабыйларны кочаклап алып: «Мин сине яратам. Валлаһи мин сине яратам!» – дип сөяр иде».

Әбү Һурайрадан мондый риваять китерелә: «Аллаһның илчесе (с.г.в.) үзенең оныгы әл-Хәсән ибн Алины үпкәндә, әл-Әкра ибн Хәбис аның янында була һәм әйтә: «Минем 10 балам бар һәм мин аларның берсен дә үпкәнем юк». Пәйгамбәребез (с.г.в.) аңа карый да: «Башкаларга мәрхәмәтле булмаган кеше үзенә карата да яхшы мөнәсәбәт көтә алмас», – ди.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) балалар белән һәрвакыт сабыр һәм игътибарлы булган. «Мин пәйгамбәребезнең (с.г.в.) кешеләр белән намаз үткәргәндә аның җилкәсендә кызы Зәйнәпнең баласын күрдем. Гыйбадәт кылганда ул оныгын җиргә төшереп тора да, сәҗдәдән соң аны яңадан җилкәсенә утырта иде», – дип сөйли ӘбүКата да.

:: Балаларга яхшы тәрбия бирү никадәр савaплы, фазыйләтле гамәл?

– Ислам дине карашы буенча, дөньяда иң гүзәл, иң мөкатдәс, иң өстенлекле гамәлләрнең берсе – балалар булдыру һәм иң савaплы эш – балалар тәрбияләү. «Балаларга кадер-хөрмәт күрсәтегез, аларны асыл кешеләр итеп тәрбияләгез», – дигән рәсүлебез (с.г.в.).

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кыз балаларны тәрбияләү хакында аерым бер искиткеч матур хәдис бар: «Кеше өч кыз бала тудырып тәрбияләсә, аларны тормышка чыгарса һәм аларга игелек кылуны дәвам итсә, ул кешенең җәннәттә урыны бар». Күрәсезме, кыз баланы тәрбияләү никадәр зур бәһагә ия! Аңлашыла ки, әдәпле һәм тәрбияле кыз бала – һәрбер мөселман гаиләсенең күрке.

Гомумән алганда, кешедә булырга тиешле иң зур байлык – тәрбия һәм әхлак гүзәллеге. «Һичбер ата баласына затлы әдәп һәм тәрбиядән башка файдалырак нәрсә бирә алмас», – дигән Аллаһның илчесе. Ә бит, чыннан да, затлы тәрбиядән дә зуррак бүләк берни юк. Балаларга калдырган мал-мөлкәт ялгышлар һәм авырлыклар аркасында юкка чыгар, ә менә гүзәл әхлак, асыл тәрбия, әдәп ул – бетмәс-төкәнмәс хәзинә. Әхлаксыз, тәрбиясез кешене беркем дә сөйми. Әдәпле һәм тәрбияле кеше, башкалардан аермалы буларак, җәмгыятьтә хөрмәт һәм дан казана. Балаларга тәрбия биргәндә моны беркайчан да хәтердән чыгармау зарур. Форсаттан файдаланып, газета укучыларыбызга иман-һидаят, тәүфыйк һәм күңел сафлыгы телим. Балаларыбызга асыл тәрбия, яхшы әдәп-әхлак бирергә Аллаһы Тәгалә ярдәм бирсен!

:: «Күчеш чоры» дигән төшенчә бар, хәзрәт. Гадәттә, бу чорда балалар тынгысыз, тыңлаусыз була. Ничек күркәм сабырлык күрсәтеп, бу чорны җиңеп чыгарга?

– Дини һәм психологик яктан караганда мондый чор бар. Бу чорда баланың психологик халәте үзгәрә, формалаша. Шуңа да ата белән ана, бала яралгач та, аны тәрбияли башларга тиеш. Шул вакытта ук бала барысын сизә, ишетә һәм тоя. Моңа мисал итеп бер гыйбрәтле бәянны искә алып үтү урынлы булыр.

Бер акыл иясе янына ата белән ана килә. Боларның яңа гына сабыйлары туган. Алар бу хикмәт иясеннән: «Безгә бу балабызны кайчан тәрбияли башларга икән?» – дип сораган. «Сез нәкъ тугыз айга соңга калгансыз», – дигән акыл иясе.

Күчеш чорында ата-ананың бердәнбер коралы – дин. Адәм баласына үзенең кем икәнен, каян килеп, кая барачагын һәм ни өчен яратылуын, яшәвен, бу дөньяда гомер сөргән вакытында йөрергә тиеш юлын, үзе өчен нинди нәрсәләр зарарлы һәм нинди эшләр файдалы икәнлеген нәкъ менә дин төшендерә.

:: Балаларның бу чорда кызыксынулары да сәер була. Төрле төркемнәргә, юнәлешләргә бирелергә мөмкиннәр. Йөз-кыяфәтләрен кабул итмиләр, үзләрен үзгәртергә телиләр әле алар...

– Яшь үзенчәлегенә кагылышлы бу чорда мондый сәерлекләр балаларда гына түгел, өлкәннәрдә дә күзәтелә. Галимнәр һәм тәҗрибәле кешеләрнең фикерләренә карап эш итсәк, шуны әйтергә кирәк: мондый кискен, четерекле мәсьәләләрдән бары тик дин һәм гаилә бердәмлеге генә саклый ала. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: «Барчагыз да бер булып Аллаһның арканына тотыныгыз, таркалып аерылмагыз», – ди.

Яшьләрнең үзләрен үзгәртергә теләүләре, йөз-кыяфәтләрен кабул итмәүләре ул – үзләрен берникадәр яклау, күрсәтү теләге, психологик халәте. Димәк, аларга ата-анасы, якыннары, җәмгыять тарафыннан игътибар җитеп бетми. Алда әйтеп үтелгәнчә, балаларыбыз белән ачыктан-ачык сөйләшү, аңлашу кирәк. Аллаһы Тәгалә: «Без кешеләрне иң яхшы кыяфәттә бар кылдык», – ди. Йөз-кыяфәтебезне үзгәртүнең кайбер очраклары гөнаһ санала. Киңәшем шул: балаларыбызга карата бу авыр чорда аеруча сабыр булырга, аларны читкә типмичә, тыгыз элемтәдә булып, яратып аңлашу мәслихәт.

Гыйбрәт ал!

Бәрәңгедән – аерылышуга

Ире эштән кайтуына хатыны бәрәңгеге кыздырган икән. Көндезге мәшәкатьләрдән төшенкелеккә бирелгән ирнең күңеле тагын да ямансулана, чөнки килеп керүгә үк ул... бәрәңге көйгән исне сизеп ала. Өстәл янына утырып, кашык белән табаны бераз актарып алгач, ир сүз башлый.

– Янган бит бәрәңгең...

– Янса ни! Ризык түгелмени?! Тамагыңнан үтмичә калмас! – дип кырт кисеп җавап бирә яшь хатын, иреннәрен усал кысып.

Болай да сөмсере коелып кайткан ирнең чырае тагын да караңгылана, һәм ул ачу белән:

– Синекеннән, бәлки, үтәр, ә мин бу күмерне ашамыйм! – дип дагъвасын белдерә дә, кашыгын өстәлгә атып, торып китә.

Хатын үзендә ниндидер гаеп булуын күңеле белән тойса да, шактый вакыт аш-су бүлмәсендә мәш килеп ризык әзерләгәнен һәм таба плитәгә утыртылганнан соң әнисе шалтыратканын исенә төшергәч, үзен акламакчы булып:

– Вакытында кайталар аны! Кеше төсле йөрсәң, ризыкка да бер нәрсә булмас иде! – дип кычкырып җибәрә.

Залдагы диванга яткан ирнең күңелендәге пәрие кубып, аны янә аш-су бүлмәсенә чыгара:

Балтач районының Арбаш авылында яшәүче Айнур Ибәтуллин җәйне болында йөреп уздыруына бер дә үкенми. Чыбыркыны оста шартлатырга да, сыерларны көтү тәртибенә дә өйрәнгән ул. Шулай булмый ни – көтүгә чыга башлавына 5–6 ел бит.

– 5 нче сыйныфта укыганда: «Акча түлибез, чык инде», – дип хуҗалык көтүенә чакыра башладылар. Ул вакытта көн саен 500 сум бирәләр иде. Мин аны әнигә алып кайтып бирдем. 7–8 нче сыйныфларда укыганда ярты җәем көтүче булып үтте. Аның караву 30 мең сумга якын акча эшләдем. Телефон, сәгать алдым, – дип сөйли Айнур.

Айнур әйтүенчә, көтүче булыр өчен түземлек тә, табигатькә соклана белү дә кирәк. Үзе исә эссседә кигәвен очканын, суыграк көннәрдә кошларның яңгырдан качуын күзәтергә ярата икән. Кыскасы, матурлыкны күрә белә. Аның белән авылда мал-туарның кимүе турында да гәпләшеп алдык. «Хәзер көтүчеләргә кытлык. Күп җирдә электр көтүче куела. Моның бер мәгънәсен дә күрмим. Бездә дә бар иде ул, тик аны кире алдылар. Андый кысанда сыерлар иркенләп йөри алмый. Авыл халкы хәзер сыердан сарыкка күчә башлады. Көтүгә чыга башлаган еллар белән чагыштырганда, сыерлар 4 тапкыр кимеде. Хәзер аларның саны – 31. Авылыбыз артык зур түгел», – ди көтүче егет.

Айнурга хезмәте өчен көнгә 1 мең сум акча түлиләр. Аның өчен бик әйбәт акча бу. Тик көн саен көтүгә чыгу физик яктан ардыра, ди. Айнур да, акча җыеп, машина йөртү курсларына язылмакчы. Тагын бер елдан мәктәпне тәмамлый. Казан дәүләт аграр университетына укырга керергә ниятли. Хезмәт тәрбиясе турында сүз чыккач, фикерен олыларча әйтеп куйды. «Әтиләр ул-кызларына эш кушканда, әниләр, «юк, үзем» димәсен иде. Икең бер булу кирәк. Безне әти-әни, өйрәнгәнең үзең өчен, дип тәрбияләде», – ди Айнур.

Буа районының Кайбыч авыл җирлеге башлыгы Сиринә Нуретдинованың кызы Чулпан да иркәләнеп кенә ятмый, җәен ындыр табагында уздыра.

– Узган ел эшләп карадым. Әти-әнигә әйткәч, каршы килмәделәр. Авыр, ләкин булдыра алырлык, мин тик ятарга өйрәнмәгән. Авыл баласы булгач, тузаннан куркып тормадым. Син бит – рәис кызы, ник эшләп йөрисең, диючеләр юк. Эшнең оятын күрмим. Быел тагын барачакмын. Ай ярымга 30 мең сум хезмәт хакы алгач, сөендем инде. Беренче хезмәт хакыма телефон алдым. Хәзерге вакытта көлияттә икенче курста укыйм. Киләчәктә башлангыч сыйныф укытучысы булачакмын. Укыганда исә репетитор булып эшлим. Мәктәпкә кермәгән балаларны укырга, язарга өйрәтәм. Студент булгангамы, акчаның кадерен беләм, – ди Чулпан.

Сәрия МИФТАХОВА

Сәрия МИФТАХОВА

БЕЗНЕҢ ТУЙ

Кемнәр исән, кемнәр юк икән? Ел буе сагынып көткән Сабан туйлары да килеп җитте. Сагынышканбызмы, сөйләшер сүзләребез бик күп җыелганмы? Мәйданга чыгып, борынгы көйләрне искә төшереп бер биеп алабызмы? Яшьләрнең дә, өлкәннәрнең дә күңелен җилкетә белә бит ул. Олы авылга гына түгел, кечесенә дә кирәк Сабан туе. Милли бәйрәм безне бер-беребезгә ни дәрәҗәдә якынайта?

«Татар-информ»

Колга башына – гармун белән

Кемдер Сабан туен туганнары, дуслары белән очрашырга дип көтеп алса, Арчада яшәүче 69 яшьлек Илфат Әскәров өчен ул колга башына менәр өчен кирәк. Багана очында башы белән дә басып торганы бар аның. Үзе белән гармунын да алып менә әле ул. Берничә секунд эчендә биек колга башында була инде ул. Халык аңа юкка гына «маймыл» дип кушамат такмаган, димәк. Илфат абый җәен 4–5 Сабан туенда катнашмыйча калмый.

– Элеккеге кебек гайрәт ташып тормаса да, Сабан туена кыш буе әзерләнәм. Өйдә 15 ел элек колга ясап куйган идем, шунда шөгыльләнәм. Төрле күнегүләр ясыйм, стадионга да барам. Көнгә 1–2 сәгать вакытымны кызганмыйм. Ният булса, җиңү дә көттермәс, – ди оптимист Илфат әфәнде.

Бәйрәмнән бүләксез кайтканы юк аның. Әтәчләрне дә шактый алган, иң зур бүләге – скутер. Колга башына менәр өчен хәйләкәрлек тә кирәк. Аяклары шумасын дип балчык, май, сагыз сөртүчеләр дә бар икән, әмма бу гына булышмый. Тырышмасаң, нәтиҗәгә ирешеп булмый. Илфат абый әнә шулай ди. Аның фикеренчә, Сабан туе ихтыяр көче тәрбияли. Ә яшьләр өчен бу бигрәк тә мөһим. Шуңа күрә милли бәйрәмебез ел саен уздырылырга тиеш дип саный ул.

Сөенеч

Арча районындагы Югары, Урта, Түбән Пошалым авылларында соңгы елларда Сабан туе уздырмаганнар. Сала халкы моның өчен ничек борчылганын үзе генә белә. Әлеге өч авылда барысы 261 хуҗалык исәпләнә. Шунысы сөенечле: халык саны кимеми икән.

– Быел бергәләп оештырырга булдык. Яме бер китсә, бөтенләй бетә бит ул. Өйдән-өйгә кереп, бүләк җыйдык. Авыл эшмәкәрләре дә кушылды. Өч авылныкын бергә уздырачакбыз. Кунакка кайтыгыз, – ди Үрнәк авыл җирлеге башлыгы Васыйл Габделхаков. – Бездә булдыклы, һөнәрле халык яши. Эшли белгәч, бәйрәме дә булырга тиеш. Сабан туе авылны саклаучы чара булып тора. Бер очрашу үзе ел буенча җитәрлек тәэсирләр калдыра. Аның кыйммәте шунда.

Актаныш районының Чиялек авылында да быел кечке Сабан туе үткәрмәкчеләр. Соңгы вакытта туктатылып торган икән. Анда нибары 12 йортта гына кеше яши. Калган йортларның күбесе буш. Шәһәрдә яшәүчеләр җәй көне авылны сагынып кайта.

– Авыл халкы җыелыша, бергәләп бүләген ала. Балалар йөгерешә, капчык киеп чаба, чүлмәк вата… Сабантуй бик кадерле мизгелләр бүләк итә. Бер-берсен сагынышкан авылдашлар туйганчы гәпләшә. Азрак аралашкан саен элемтәләр югала бит ул. Менә шуны югалтмаска иде. Сабан туе кирәк. Кечкенә авыл, зур авыл дип бүлеп карарга ярамый. Икесендә дә – шундый ук проблемалар. Сабан туе узгач, юлны төзекләндерә башлаячакбыз, – ди Иске Айман авыл җирлеге башлыгы Марсель Әхмәтханов.

Французга да, алманга да кирәк

Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылында быел хатын-кызлар бил алышырга чыкмаячак икән. Элек көрәшеп йөргән апалар инде олыгаеп бара. Яшьләр исә сөлге тотарга теләми. Әмма мәйданда көч күрсәтергә ярышлар болай да җитәрлек. Ике потлы герләрне 150шәр тапкыр күтәрүче егетләр бар. Чит ил кунаклары өчен дә кызык монда. Берничә ел элек Германия, Франциядән дә кунаклар килеп, милли йолаларыбыз белән танышып киткән. Сабан туена бүләк җыю бәйрәмендә дә катнашканнар. Алман хатын-кызлары көрәшеп тә караган хәтта.

Күгәрчен дә булсын, күгәрчене дә булмасын ди?! Авылда Сабан туен ак күгәрченнәр очырып башлау гадәте бар. Монда берничә хуҗалыкта күгәрчен асрыйлар.

Яшел Үзән районының Бакырчы авылында мотоблоклар ярышы узачак. Сабан туена бүләкне әнә шуларга утырып җыеп йөргәннәр быел. Авылда ат асраучылар юк, шуңа күрә мотоблокны эшкә җиккәннәр. Аны «Бакырчы» дип язылган чигүле сөлгеләр белән бизәп, милли киемнәр киеп, оештыручылар өйдән-өйгә йөргән. Быел узачак бәйрәм «Мөселманнар җыелган җирдә» дип атала. Бергәләп намаз, Коръән аятьләре уку да булачак. Шулай ук милли ярышларга да урын биреләчәк. Кер, катнаш, бүләк от! Һәр авылда Сабан туеның бизәге бул!

…Бүләгем сиңа булсын!

Сабан туена бүләк җыюның үз тәртибе бар. Республика районнарында әлеге йоланы ничек үткәрәләр икән?

Балтач районының Чапшар авылы:

Балтач якларында Сабан туена бүләк җыю күренеше «Әрәпә» дип атала. Бала-чага, яшьләр һәр капка төбенә килеп җиткәч, шулай дип кычкыра. Хуҗабикәләр шуны ишетеп урамга чыгып бүләген тапшыра. Чапшар авылында, бәйрәм тагын да ямьлерәк булсын дип, быел хәтта икешәр ат җиккәннәр. Аллы-гөлле чуклар белән бизәлгән бахбайлар матурлык бәйгесенә барырга җыенганмыни?! Арбага менеп кунаклаган кечкенә балаларны бәхет баскан. Болай әле тагын кайчан урам әйләнерләр иде. Гармунчылар да бераү түгел, берничә. Капка төпләрендә әбиләр биеп, яшьлекләрен искә төшерә. Бу авылда «Чабата»ны бик оста биилэр.

Кукмара районының Мәмәшир авылы:

«Сөлге җыю» йоласына сәгате килеп җиткәч кенә түгел, кемнәрдер еллар буе әзерләнә. Ни өчен дигәндә, монда гадәт буенча киленнәр – чиккән сөлге, яшь кызлар кульяулык бирергә тиеш. Кияүгә чыкмаган кыз яшәгән йортның капка төбенә килгән егетләр: «Чиккән кульяулык», – дип кычкыра. Кыз аны үзе теләгән егетнең биленә тагып куя. Яшь киленнәр сөлгене колгага үзләре бәйли. Оялчанракларына каенаналары булыша. Кыскасы, чигүче кызлар, кәләшләр авылның күрке булып тора. Элек халык оек, ситсылар бирсә, хәзер юрган, табак-савыт ише әйберләр бүләк итә. Клуб мөдире Сүрия ханым, фәлән апаның биргән бүләге өчен, дип әйтүгә, бүләк җыючылар «ура» дип кычкыра. Авылда чәй куеп, коймак пешереп сыйлаучы гаиләләр дә бар.

Тукай районының Борды авылы:

Монда яулык җыю йоласы алдан түгел, бәйрәмгә бер көн кала уза. Халык шулай гадәтләнгән. Бүләккә яулык, сөлгеләр, көнкүреш кирәк-яраклары, чәй сервизлары, хәтта әтәч, куян бирүчеләр дә бар икән. Йомырка да онытылмый. Анысы да уеннарда катнашучыларга эләгәчәк. Өлкәннәр ил-көнгә тынычлык теләп, дога кылып, сөлгеләрен колгага үзләре бәйли. Яңа өйләнешкән парлар да бүләк әзерли. Бала-чагага күчтәнәч өләшәләр. Кемдер кәнфитләрне махсус җиргә чәчә икән. Балалар бер-берсен уздырып, мәш килеп шуны җыя.

МАРСЕЛЬ ТАҺИРОВ:

«Сабан туенда чикләү юк, мәйдан һәркемгә җитә»

Сабан туе мәйданына теләгән һәркем чыгып көрәшә алсын! Татарстанның көрәш федерациясе районнарга әнә шундый тәкъдим белән хат юллаган. Федерациянең башкарма директоры Марсель Таһировның батырлар һәм бүләкләр турында фикерен белештек.

– Сабан туе – туганлашу, дуслашу, халыкны берләштерү бәйрәме. Теләгән һәркем бил алышсын, бәйрәмдә үпкәләүчеләр булмасын дип районнарга хат юлладык, – ди Марсель Таһиров. – Батырлар бер Сабан туеннан икенчесенә йөреп, бүләк җыя дисезме? Узган атнада гына дистәгә якын авылда бәйрәм узды. Бу әле мин белгәне генә. Бу елларда бөтен Татарстанда бәйрәм итәләр. Мәйдан һәркемгә җитә. Шуңа күрә күпме көрәшә алалар, шуның кадәр бил алышсыннар. Берниндә чикләү дә була алмый. Бу хакта, гомумән, сөйләшүнең дә мәгънәсе юк. Әйе, авыл бәйрәмендә шунда яшәгән, тир түккән егетләр батыр кала алмый, чөнки профессиональ спортчы дәрәҗәсендәге көрәшчеләр килеп, барысын да егып сала, бу гадел түгел дигән фикерләр дә ишетелә. Бер яктан карагында, монда күпмедер дәрәҗәдә хаклык та бар. Шуңа күрә кайбер якларда авыл егетләрен һәм кунак булып килгәннәрне аерым көрәштерәләр. Икенче яктан, шөгыльләнәм дигән кешегә шартлар җитәрлек бит хәзер. Әзерләнсеннәр, бил алышсыннар.

– Сабан туйларында батырларга бүләкне дә мулдан өләшәләр. Олы бүләк гаделлеккә зыян салмыймы?

– Беләсезме, бүләкләр белән элек тә, хәзер дә кызыксынган юк. Барысы да гадел булсын өчен болай эшләр идем: һәр үлчәү авырлыгында җиңүчеләргә бер үк бүләк бирәсең. Әйтик, 30 мең сум акча. Баш батырның иңенә исә тәкә саласың, – ди Марсель Таһиров. – Ни генә әйтсәләр дә, шөкер, келәмгә чыгып бил алышырлык егетләр күп бездә. Узган атнада Минзәлә районындагы Калморзада Авыл көне узды. Күрше-тирәдәге 6 районнан җыелган 75 егет бил алышты анда. Хәтта җиңелгән малайларның да һәрберсенә 500әр сум акча өләштеләр. Карап торам: бер-берсен этә-төртә келәмгә чыгаралар. Менә бу – үрнәк алырлык вакыйга. Мәйданга чыккан һәр кешенең бүләк аласы килә. Балаларның бигрәк тә.

АВЫРУ ХАТЫНЫН ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ АЗАТ АБЫЙ:

«СӨЙЛӘШӘ АЛМАСА ДА, РӘХМӘТ ӘЙТӘ»

Күпләр, сынау килгәч, югалып кала. Вәгъдә һәм бурычлар онытыла, сынау җилләре мәхәббәт сүзләрен таратып юкка чыгара. Авыру баласыннан баш тартучылар, сәламәт чагында сөеп туя алмаган хатынын, ул урынга калгач, ташлап чыгып китүче ирләр бар. Ә менә Минзәлә районының Яңа Иркәнәш авылында яшәүче Азат Шәкүровның язмышын ишетеп, сокланмый мөмкин түгел. Башкаларга гыйбрәт булырлык итеп яши ул.

– Дусларыбызның туенда таныштык. Шаһитлар идек. Тәслияне бер күрүдә яраттым. Шулай итеп очраша башладык. Гаилә кордык, бер кыз, бер ул үстердек, – дип башлады ул сүзен. – Хатынымның кинәт авырый башлавы арабызны суытмады. Киресенчә, мин аңа терәк булырга тырышам. Кимсенмәсен, үзен яратуларын тойсын дип яшим. Хатынымны мин карамый, кем карасын?!

Тәслия апа 1993 елда авырый башлый. Гомеренең чәчәк кебек чагы, яңа гына 40 яше тулып киткән була. Башта бер аягы аксаклый, аннан – икенчесе. Башта таякка таяна, аннары ходункига тотына. Күренмәгән табиблары калмый. Алар Тәслия апага «рассеянный склероз» дигән диагноз куя.

– Баштарак хатыным өйдәге эшләрне үзе башкарырга тырышты. Чәй кайнатып эчә, үзе тотып ашый иде. Тик 10 еллап инде ул кеше ярдәменә генә мохтаҗ. Ашый да алмый, киендерергә, юындырырга, чәчләрен тарарга, хәтта тешен чистартырга да кеше ярдәме кирәк. Яныннан китмим, үз хатыным бит. Ничек инде ул, йөгереп йөргәндә, гаиләне кайгыртканда кадерлисең дә, авыргач, ташлап китәсең. Аллаһы Тәгаләдән куркырга, балаларыңнан оялырга кирәк, – ди Азат абый.

Тәслия апаның бертуган апасы да нәкъ шушы авырудан интегә. Аны килене тәрбияли икән. Азат абый ул киленгә соклануын яшерми, «әни» дип өзелеп тора, ди. Үз кызына да рәхмәтле ул. Әгәр кызым атна саен кайтып ярдәм итмәсә, киявем аңламаса, бер үземә кыен булыр иде, ди. Соңгы арада Тәслия апаның сөйләшүе дә начарайган. Әмма рәхмәт сүзен еш кабатлый икән.

– Тәслия бит ул барысын да аңлый, күреп тора. Шуңа да без аны бик кадерлибез. Күңеле төшмәсен, дибез. Хатынымны ташлап беркая чыгып китә алмыйм. Дөрес, хөкүмәт аны караган өчен акча түли. Әмма ул бик аз. Җитәкчеләргә шуның өчен бераз үпкәм дә бар, күтәрсеннәр иде ул акчаны. 1200 сум кибеткә бер мәртәбә кереп чыгарга гына җитә бит ул хәзер. Әле ярый умарта тотам. Тормыш итәргә анысы ярап куя, – ди Азат абый.

Азат абый һәр иртә уянуга хатынының битен юа, аннары чәчләрен тарый. Ашарга әзерләп, аны кашыклап ашата. Гәүдәсе көннән-көн тыңламый икән. Әмма ире сабыр итә.

– Язмыш һәркемне үзенчә сыный. Дөньялыкта ничек тә яшәрбез, Аллаһы Тәгалә каршына барасын да онытмыйк. Якын кешеңә ярдәм итә алуыңа сөенергә кирәк. Хатын-кыз булачак иренә ышанып кияүгә чыга. Аның канаты астында яшәрмен дип уйлый. Шуңа да чын ир булып, сөеклебезне яклап, саклап яшәсәк иде, – ди ул.

Рәхмәт ишетү рәхәт

Казан күреп кайттык

Балтач районында инвалидлар оешмасы белән берлектә инде унсигез ел «Фикердәшләр» клубы эшләп килә. Шөкер, анда йөрүчеләр елдан-ел арта. Монда йөрүче мөмкинлекләре чикле кешеләрнең тормышка карашы нык үзгәрде. Без һәр чарада очрашып торабыз. Ел әйләнәсе клубта күп бәйгеләр, ял итү чаралары, бәйрәмнәр оештырабыз. Безгә «Факел» яшүсмерләр клубы хезмәткәрләре гел ярдәм итеп торалар.

«Фикердәш»ләр җырчылар белән дә дус. ИлГәрәй безне аеруча якын итә. Бездә үткән бәйрәмнәрдә гел матур җырлары белән куандыра. Әле менә шушы көннәрдә ул үзенең филармониядә узган зур концертына безне дә чакырды. Бу залны беренче тапкыр күрдек. Җырчының мөмкинлекләре чикле кешеләрне дә аңлап концертка дәшүенә бик сөенеп кайттык. Без аңа һәм иҗатташ дусларына чиксез рәхмәтле.

Шушы концертка баруны оештырган район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илһам Гайнетдиновка, «Хәс» оешмасы җитәкчесе Фәһим Сибагатуллинга, Балтачның «Нур» мәчете имамы Илгиз Әхмәдуллинга олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

Әмма күңелдә китек калды. Филармониядә безнең кебекләр өчен уңайлы мохит булдырылмаганына борчылдык. Шунда эшләүче егетләр безне никадәр озын баскычтан коляскада күтәреп мендерәләр. Киләчәктә башка концерт залларындагы кебек уңайлыклар тудырылсын иде.

Чулпан ГАБДЕЛГАНИЕВА.
Балтач районы

Филармония директоры Кадим НУРУЛЛИН белән элемтәгә чыктык.

– Безнең бина 1939 елда төзелә башлап, 1967 елда гына кулланууга тапшырылган. Бинаның шул чор архитектурасы саклана. Лифт куярга мөмкинлек юк. Дөрес, физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне коляска белән күтәрә торган машинабыз бар. Әмма ул бик уңайсыз эшләнгән. Өске катка мендерү өчен 10 минут вакыт кирәк. Әле шуны-сы да бар: кеше ул машинага утыргач, артка таба ятып барырга тиеш. Хат авторы борчылмасын, безнең егетләр аларны һәрвакыт каршы алырга әзер, – диде ул.

Оныклар хакына

Яшел Үзән районының Новониколаевка авылында яшәүче Гөлсинә апа Калатаева, яшәр өчен көчне оныклардан алам, ди. Узган елның октябрь аенда аның улы белән килене, мунчадан чыга алмыйча, янып үлгән. Ул бу хакта әле дә еламыйча сөйли алмый. Оныклары исә әбисенең күз яшьләрен сөртеп тора...

Никадәр авыр булса да, Гөлсинә апа, ачы хәсрәтен эчкә йотып, оныклар белән елмаеп яшәргә тырыша.

– Улым белән киленемнең икесенә биш бала ятим калды. Ксениянең кияүгә килгәндә өч кызы бар иде. Улым белән яши башлагач, игезәк уллары туды. Без бик тату, матур яшәдек. Сабыйларны да тигез күрдек. Ул көнне мин оныклар белән өйдә калдым. Алар мунчага китте. Төтен исен сизеп алдым. Төн уртасында бу балалар нәрсә эшли икән дип урамга чыксам, мунча дөрләп яна, – дип искә ала ул.

Ул чакта гаилә йорт төзи башлаган була. Аны җиткергәнче, кечкенә генә вагонда яшиләр. Анда балалар өчен дә бар мөмкинлек була. Фаҗигадән соң, район опека бүлегеннән килеп, ике малайны приютка алып киталәр. Ксениянең өч кызын әнисе ала.

Пенсиядә булса да, эшләп йөргән Гөлсинә апа. Сәламәтлеге буенча да кимчелекләр табылмый. Сабыйларны үзенә алыр өчен документлар җыя башлый. Торыр җирнең тиешле таләпләргә туры килмәве аркасында ул оныкларын ала алмый. Шуннан соң аның язмышы ил буйлап тарала.

– Кодагыйның ярдәм итәргә балалары, туганнары бар. Мин берүзем идем. Шөкер, аралашып яшибез. Мин дә игезәк малайларны үземә рәсмиләштереп, опекун булдым. Оныкларны ятимнәр йортына җибәрмәгән өчен, мин бөтен дөнья халкына рәхмәт әйтәм. Бик авыр чагымда волонтер Юлия Хәкимова ишегемне шакыды. Хәлләремне сорашты, ярдәм итәргә сүз бирде. Минем ничек яшәвемне телевизордан күрсәттеләр. Әлеге сюжетны карап, миңа ярдәм итәргә теләүчеләр табылды. Мин инде өметемне өзгән идем, – ди ул.

Юлия Хәкимова акча җыюны оештырып, ризыклата, кирәк-ярак белән ярдәм итеп кенә калмый, ул үзе белән бер төзелеш оешмасы җитәкчесен дә алып килә. Егетләр килеп карагач, Калантаевлар сала башлаган өйне сарай итеп калдырып, яңа йорт төзергә карар кыла.

– Төзелеш оешмасы җитәкчесе Ильяс Гыймадовка чиксез рәхмәтемне җиткерәм. Иң зур эшне алар башкарды. Без хәзер матур йортта яшибез. Бөтен уңайлыклары бар. Сабыйлар сөенеп туя алмый. Ичмаса, торыр җиребез булды, – ди әбиләре. – Ничек кенә тырышсам да, әти-әниләрен алыштыра алмыйм. Әниләрен сорап елаган чаклары да күп. Кайчак юатыр сүзләр таба алмыйча, иреп елыйм. Әмма яшәргә кирәк. Малайлар барысын да аңлый, зиратка да еш йөрибез, – ди Гөлсинә апа.

Малайларга 7 яшь тулган. Әмма әбиләре, быел мәктәпкә җибәрмичә торам, ди. Психологлар шулай киңәш иткән.

– Иң мөһиме – авырмасыннар гына. Калганын ничек тә булдырырбыз. Көн саен бер теләк белән уянам: Аллаһы Тәгалә сабыйларны үстерерлек көч, сәламәтлек, гомер бирсен иде, – ди ул. – Җиде ай эчендә минем тормышка бөтенләй карашым үзгәрде. Җир йөзендәге миһербанлы кешеләрнең күплегенә шаккаттым. Өй кадәр өй салып бирсеннәр әле! Күпме кием, ризык китерделәр. Барысы алдында баш иям. Сезгә мондый хәсрәтне кичерергә язмасын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

РӨСТӘМ ГАЛИУЛЛИН:

«БУ ЭШЕҢ СИНДӘ ЯЗУЧЫНЫ ХАРАП ИТӘ, ДИП МИҢА ЕШ ӘЙТӘЛӘР ИДЕ»

Газета-журналлар укучыга иярергә тиешме, әллә киресенчәме? Массачыл әдәбиятның урыны кайда? Гомумән, әдәбиятны бүлгәләү дөресме? Болар һәм башка мәсьәләләр хакында «Казан утлары»ның баш мөхәррире Рөстәм ГАЛИУЛЛИН белән сөйләштек.

:: «Казан утлары» 100 еллык зур бер сәхифәсенә нәтиҗә ясады. Киләсе йөз еллыкны нинди уй-ниятләр белән башлап җибәрдегез? Журналның юнәлеше үзгәрәчәкме?

– Йөз еллыкны без тарихны барлап, әзерләнеп каршыладык. Артка борылып карасак, «Казан утлары» узган гасырның егерменче елларында «Безнең юл» дигән атама белән чыга башлаган. Бүгенгә килеп җиткән басманың, күпме генә баш мөхәррирләре алмашынса да, редакция составы үзгәреп торса да, төп уңышы – оештыручысы Галимҗан Ибраһимов билгеләгән юнәлештә. «Казан утлары» – әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал. Мин аны бәхетле журнал дип атыйм. Чөнки нәшер ителә башлап та, туктап калган, укучысын таба алмаган басмалар шактый. Ә «Казан утлары» – әдәбият сөючеләр басмасы. Монда яшь тә, җенес тә, нинди һөнәр иясе булу да мөһим түгел. Басма гаиләгә бер кергән икән инде, буыннан буынга күчеп бара. Башта аны әби-бабай укый, аннары ата-ана, алардан соң балалары алдыра башлый. Андый гаиләләр кимүгә таба барса да, алар әле бар. Шулай ук ул – укытучыларның, әдәбият юнәлешендәге һөнәр ияләренең дә журналы. Димәк, без конкрет укучыларыбызны белеп эш итәбез. Әлбәттә, без белмәгәннәре дә бар, алары да безгә кызык, даими өйрәнәбез, кызыксынабыз. Максатыбыз исә йөз елдан соң да шул булып кала – татар укучысына бүгенге язучыларның яхшы әсәрләрен бастыру, әдәби-иҗтимагый процессны күрсәтү.

Заман белән бергә без дә үзгәрәбез. Хәзер инде үзебезне мультимедияле редакция дип йөртәбез. Төп эшебез – Россиянең 30га якын төбәгенә тарала торган журнал чыгару булса, социаль челтәрләр аша да укучыларны кызыксындыру юнәлешендә эшлибез. Көнгә сайтка 2 меңгә якын укучы керә һәм 8 меңләп карау бар икән, әдәби журнал өчен бу начар күрсәткеч түгел. Иң кызыгы – карауларның 50 проценты гына Татарстанга туры килә, калганнары Башкортстан, Мәскәү өлкәсе, Казахстан һәм башкалар. Бу ике юнәлеш бер-берсен кабатламый, алар бер-берсен тулыландыра гына. Журналда әдәби әсәрләр, публицистика урын алса, интернет челтәрендә күбрәк әдәби процесска игътибар бирелә. Әйтик, «Классика тарихы» дигән видеосәхифәне бик яратып кабул иттеләр. Без анда «Казан утлары»нда кайчандыр басылган һәм бүген классикага әверелгән әсәрләрнең язылу тарихын, язмышын бәян итәбез.

Быел Цифрлаштыру елы да бит әле. Юбилей уңаеннан безгә сканер бүләк иттеләр. Аның ярдәмендә 100 еллык архивны цифрлаштырабыз. Ул архив ачык була, аннан һәркем файдалана алачак. Төрле елларда басма гарәп имлясында да, латинча да чыккан. Тора-бара ул текстларны да кириллицага күчерергә ниятлибез. Укучыларга бер дигән бүләк бу, миңа калса.

:: Укучы дигәннән, газета-журналларның тиражлары сизелерлек төште, кайбер басмалар интернетта гына «яши» башлады. Кайберләре бөтенләй ябылды. Бу шартларда журналны ничек саклап калырга?

– Элек мин басманы укучыга җиткерергә, күрсәтү, аңлату эшләре алып барырга кирәк, дип уйлый идем. Алай гына түгел икән. Иң беренче чиратта контентны кайгыртырга кирәк. Яхшы, укылышлы әсәр язылган икән, аны бастырырга һәм танытырга кирәк. Таныту өлешен «Татмедиа» үз өстенә алганнан соң, безнең эшләр шактый алга китте. Шуңа күрә соңгы елларда, Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырганда бигрәк тә, безнең әдәби журнал иң зур тиражлы санала. Югыйсә кайбер журналларның тиражы бер меңгә төште, туктап калганнары да җитәрлек. Безнең исә, әйткәнемчә, хөкүмәт ярдәме белән дә, «Татмедиа»ның төрле алымнары бәрабәренә дә, хәлебез начар түгел. Әйтик, берәмләп сату шактый алдырып китте. Журнал вендинг аппаратларында, маркетплейсларда сатыла, чит төбәкләргә, бигрәк тә Башкортстанга күпләп тарала. Болар нәтиҗәсен бирә башлады, тираж әлегә артуга бара.

> Соңгы елларда журналда яхшы мәгънәсендәге гаугалы әсәрләр дә дөнья күрде. Әйтик, Фәүзия Бәйрәмованың «Гөләйза» романы чыккач, кайтавазлар шактый булды. Ринат Мөхәммәдиевнең «Ак кәгазь нидән саргая?» дигән романы да шау-шу тудырды. Равилә Шәйдуллина-Мурат романы да битараф калдырмады. Иң кызыгы, шундый әсәрләр чыкканнан соң, тираж үсеп китә. Бу инде эчтәлекнең никадәр мөһим икәнен күрсәтә.

Алдагы айларда да укучыны «селкетеп» җибәрә торган әсәрләр басылачак. Әйтик, июльдә Зөлфәт Хәкимнең әдәби конкурста җиңү яулаган әсәре басылып чыгачак. Без халык яраткан авторлар белән элемтәдә торып, хәл-әхвәлләрен белешеп торабыз. Әйтеп яздырган чаклар да була. Ник дигәндә, алар безнең журналның тоткасы инде.

:: Тел комиссиясе ярдәмендә оештырылган «Әдәби конкурс» журналга яңа сулыш өстәде кебек.

– Әле ничек кенә! Мең ярымга якын әдәби әсәрнең 15е роман иде. 1–3 урыннар алган романнар июльдән басыла башлый. Повестьлар, поэмалар инде басылып бара, шигырь, хикәяләрне бастырып бетердек. Хәзер инде конкурс һәм жюри эшенә укучылар да бәя бирә ала. Чыннан да, әйбәтме ул әсәр, юкмы?

Яшерен-батырын түгел, гонорар күләме бөтен җирдә дә бик түбән. Гомумән, гонорар системасы җимерелде, дип әйтсәк тә була. Ул нибары өч республикада – бездә, Башкортстанда, Якутиядә күпмедер дәрәҗәдә сакланып калды. Язучы бушка эшли алмый, аңа да бит тормышны алып барырга кирәк. Бу конкурс исә аларны илһамландырып җибәрде. Нәтиҗәдә ел ярым вакыт эчендә 15 роман туды. Бу күләмдә Россиядә, мөгаен, рус телле язучылар гына язадыр. Акрынлап, әлеге конкурста җиңгән әсәрләрне генә түгел, алга таба яхшы дип табылганнарының барысын да чыгарып бетерәчәкбез. Алар – безнең байлыгыбыз.

Байлык дигәннән. Бүген укучыга 13 нче кесә китабы әзерләнә. Хәзер инде һәр китапның тиражы 3 меңгә җитте. Халык яратып кабул иткән, «Казан утлары»нда басылган әсәрне китап итеп чыгару күптәнге хыял иде. Аннан соң язучыга китап чыгару да җиңел эш түгел бит, нәшриятта аңа чират та зур. Без исә аларга шундый мөмкинлек бирәбез. Яхшы язып та, тыйнак кына күләгәдә калганнарны да танытасыбыз килә. Чит төбәкләрдәге авторларга да игътибарны

Блиц-сораштыру

– Соңгы укыган китабыгыз?
– Эш буенча көн-төн укыйм, өйдә исә Николай Лугиновның «Хунские повести» әсәрен яңадан укып чыктым.
– Иртәгез нәрсәдән башлана?
– Табигатьтә йөреп керүдән.
– Соңгы язылган әсәрегез?
– Әле төгәлләнмәгән. Роман язам.
– Иң зур теләгегез нинди?
– Бала буларак та, балалар әтисе буларак та, якыннарымның исәнлеген телим.

арттырабыз. Җыеп әйткәндә, монда язучы да, типография дә, укучы да ота.

:: «Казан утлары» яшь иҗатчылар белән дә актив эшли иде бит әле. Язучы, публицист Рәфикъ Юныс башлап җибәргән «Ак җилкән» берләшмәсе бүген ни хәлдә?

– Бу берләшмә мәктәп балалары арасында хикәяләр яздырып карау, өметле яшьләрнең иҗатын тәкъдим итү белән шөгыльләнә иде. Әмма моннан 2–3 ел элек без, төрле журналлар, бер-беребезне кабатламас өчен, кайбер сәхифәләрне туктаттык. Мәсәлән, «Казан утлары» кайчандыр «Безнең мирас» журналы белән бик якынайган иде. Хәзер инде «Безнең мирас» журналы үзенең өлешенә китеп бара, «Казан утлары» журналы күбрәк хәзерге әдәбиятка басым ясый. Ә инде яшьләр белән «Ялкын», «Идел» журналлары эшли. Шулай да без күзгә күренеп торган яшьләр өчен «Җәһәт тәнкыйть» сәхифәсен ачтык. 15–20 яшьлекләрнең хикәяләренә урын биреп, янәшәсендә үк галимә Дания Заһидуллинаның әсәргә анализын бирдек. Тәнкыйте усал булса да, яшьләр аңа рәхмәт укыйлар иде. Ахыр чиктә, талантлы яшьләрне бер кат анализлап чыкканнан соң, сәхифә «Бергәләп укыйбыз» дигәнгә әйләнде.

:: Заман белән бергә укучы да үзгәрә. Сезне хәзер күбрәк кемнәр укый?

– Сайт турында сүз барса, анда иң күп укучы – 45 яшьләрдәге хатын-кыз һәм илле яшьләр тирәсендәге ир-ат. Икенче төрле әйткәндә, бу – тормыш корган, үзен тапкан, ниндидер формада биеклек-дәрәҗәләргә ирешкән, гармониядә яши торган кеше. Димәк, «Казан утлары»н күпчелек очракта гаилә корып, балалар үстергән, нигезле, акыл утырткан кешеләр укый. Үзебездән карасак та, элек минем өчен көнгә бер китап уку норма иде. Бу – балачак, үсмерчак, студент еллары. Ә инде өйләнгәч, эшли башлагач, китап укырга вакыт калмады диярлек. Документаль әсәрләр генә укыла башлады. Минем уйлавымча, яшьләрнең күпчелеге шул хәлдә. Тора-бара тормыш көйләнә, билгеле бер вакытта үз эзенә яңадан кайта. Укырга мөмкинлек чыга. Шул вакытта кулга китап аласы килә башлый. Әйтик, бүген миңа 50–60 яшьлек чиновниклар, эшмәкәрләр әйбәт әсәрләр сорап мөрәҗәгать итә. Аларга төрле-төрле әсәрләр җибәреп торам. Утыз ел укыган юк иде, хәзер менә яңадан кереп киттем, күбрәк тарихи әсәрләр, милли әсәрләр укыйсы килә, диләр. Мин моңа бик сөенәм, бу – нормаль күренеш. Ул кешеләр оныклар үстерү яшендә, аларга бит рухи байлык та тапшырып калдырырга кирәк. Димәк, «Казан утлары» менә шундый өлгергән укучы өчен.

Ләкин яшьтән әдәбиятны яраткан кешеләр дә бар бит әле. Мәсәлән, мин «Казан утлары»н башлангыч сыйныфларда ук укый идем инде. Андый укучылар да бар. Дөрес, гомуми укучы саны кимеде, әмма сыйфатлы укучы саны артык кимемәде.

:: Журналны планлаштырганда укучыга ияру бармы?

– Бәлки бу гаебемдер, әмма мин күпмедер дәрәҗәдә укучыга иярәм. Журнал планлаштырганда традицион әсәрләр белән берррәттән, киң катлау укучыга да сюжетлы әсәрләр бирергә тырышабыз. Ул «кара» әсәр дә түгел, анда билдән түбән күренешләр дә булмый, ләкин аның авторы профессиональ язучы булмаска мөмкин. Язучылар берлегенә кермәгән, халык арасында популяр булган язучыларга да игътибар итәбез. Аларның тәүге әсәрләрен бастырабыз һәм, ни гаҗәп, аларны бик яратып укыйлар. Башлап язучыларга «Казан утлары»нда чыгу мәртәбә. Әлбәттә, бу әсәрләрне бөтен шартын туры китереп редакциялибез. Журнал галимнәр яки педагоглар өчен генә түгел, ул киң катлау укучы өчен дә. Бүген күпчелек укучыны тормышчан әсәрләр кызыксындыра. Әйтик, мин авылда бер абзыйны беләм, ул журналга Равилә Шәйдуллина-Мурат әсәрләрен уку өчен язылды. Сүз уңаеннан, ул безнең заказга яңа роман яза, инде тәмамлап та килә.

> Гомумән, массачыл әдәбият белән профессиональ әдәбият арасында чик җуелды сыман. Мисал өчен, билгеле булмаган автордан шундый әсәрләр килә, теле камил, укылышлы, милли рухта язылган. Ник аны массачыл дип әйтергә? Авторы билгеле булмагангамы? Шул ук вакытта исеме зур саналган язучы тәэсир итми торган, ниндидер ясалма сюжетлы, кызыксыз, тел йөгереклеге аксаган әсәр тәкъдим итәргә мөмкин. Анысы нинди әдәбият була?

:: «Казан утлары» дигәч, укучы күз алдына чал чәчле агайлардан торган редакция күз алдына килә...

– Чал чәчле абыйлар редакциядә әле дә бар. Элек бит редакция ничек формалашкан? Язучы төрле редакцияләрдә эшли-эшли, ахыр чиктә, шушы «Казан утлары»на килеп җиткән. Бүген өлкән буын, урта буын, яшь мөхәррирләр бар. Шунсыз булмый да, безгә бит һәр катлау вәкиле белән эшләргә туры килә.

:: Мөхәррир вазыйфасы Рөстәм Галиуллин дигән язучының иҗатына ничек тәэсир итә?

– Миңа, бу вазыйфа язучыны харап итә, дип һаман әйтәләр инде. «Идел» журналында эшли башлагач та шулай кисәттеләр. Алай түгел ул. Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимов нинди зур эшчәнлек алып барган, шул ук вакытта нинди әсәрләр язган! Гаяз Исхакый белән дә шул ук хәл. Бу олпатлар янында безнең эшчәнлек юк дәрәҗәсендә бит инде. Шулай да мөхәррирлек эшенең бер начар ягы бар: элек мин биредә ел саен басыла идем, хәзер алай түгел. Әйтик, 2017 елда гына да «Боссоойко» дигән хикәям, «Әдрән» дигән повестем чыккан, шуннан бирле бер әсәрем дә басылмаган. Юкса минем дә беркайда чыкмаган өч повестем, хикәяләрем бар. Быел, бу язучы буларак беткән икән дип әйтмәсеннәр өчен, инде ярыйдыр дип, кыска гына хикәяләрне бирдем, зурларына урын табып булмады. Мөхәррир язучыдан яхшы әсәрләр көтә. Аның вазыйфасы шул. Шунлыктан безнең мөхәррирләр, кимчелекле, җитешсез якларын күрсәтеп, дәлилләп, шактый әсәрләрне кире бора. Бу авыр йөк үземә дә шактый төшә. Шунлыктан үз әсәреңә дә таләп арта. Баш мөхәррир булгач, бигрәк тә. Шуңа, язгач та, бастырырга әллә ничек. Әйбәтме, юкмы икәнен белеп булмый бит аның. Шундыйрак хәлләр. Әмма иҗат үз юлы белән бара, бүген мин бер роман язам. Аны тәмамлану алдында дип тә әйтеп була. Ул безнең чорга, заманабыз шәхесенә багышлана.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Хатлар көтәм

Почта яшниге диләр инде аны безнең якта. Бу – коймага беркетеп оныта торган әйбер. Почтальоннар шунда гәҗит-журнал-хат кыстырып китә. Менә шундый нәрсәне миңа Мөслим районының Метрәй авылында яшәүче Рүзәл Минһаҗев дигән искиткеч шәп егет бүләк итеп җибәрде. Бик озак балконда ятты ул яшник, шуннан авыл коймасын яңарткач элеп карарга булдым. Әллә күпме кеше сокланып киткәч, чынлап элеп куйдым. Ныгытып. Матурлап. Бөтен кеше миңа сокланып китә, Рүзәлгә сокланырга кирәк. Ә бәлки миңа сокланулары да дөрестер, үзем генә мин беркем дә түгел, мин сезнең нурлар белән балкыйм бит инде. Һәм почта яшниге белән... Һәм... Дөньяның бер гади кануны бар: коймаңда почта яшниге эленеп торгач, хат көтәсең икән.

Мин дә хатлар көтәм...

Яшьрәк буын хатның ни икәнен дә белми торгандыр инде хәзер. Ак кәгазьгә каләм белән кулдан язылган сүзләрне кәгазь конверт эченә тыгасың да якын кешеләреңнең берәрсенә җибәрәсең. Әнкәңә, мәсәлән, сөйгән ярыңа, дустыңа. Тегеләр дә көтеп торадыр дип уйлыйсың. Шуннан җавап көтә башлыйсың. Җавап хаты. Күп чакларда җавап хаты килә. Сөенәсең. Кайвакытта килми. Борчыласың. Якын кешең белән бер-бер нәрсә булдымы әллә дип уйлыйсың. Мөнәсәбәтләр үзгәрдеме икән, дип тә шикләнәсең. Кайчагында үз хатың да кире әйләнеп кайта... Мондый аралашу ысулы бүгенге заман тизлегенә ияләшкән кеше өчен бик уңайлы түгел инде. Хәзер бит я смс язып җибәрәсең, я телефоннан шалтыратып сөйләшәсең. Җайлы хәзер.

Ләкин хат язышуның да үз рәхәтлекләре була торган иде. Хәер, аны рәхәтлек дип әйтү дә дөрес түгелдер инде. Хат килсә генә рәхәт була. Килмәсә, моңсуланасың, хат алучылардан көнләшәсең. Җанга сагыш саркыла.

Әле мин бәләкәй чакта да хат алышу иң зур бәйләнеш булып исәпләнә иде. Дәү әниләр үзләре укый-яза белмәсәләр дә, хат яздыралар. Авылның иң матур яза торган бер кешесе бар, аны, яратып, «писер» дип йөртәләр, хатларны да шуңа әйтеп торып яздыралар, язганы өчен акча яки чәй, күкәй кебек күчтәнәч биреп җибәрәләр. Бераз үсә төшкәч, дәү әни миннән хат яздыра да: «И, балам, бигрәк төз итеп язгансың, писер булырсың әле», – дип мактап куя торган иде. Сүзе дөреска якын булып чыкты. Мин «писер» үк булалмадым инде, язучы гына булдым.

Ә үземнең иң беренче язган хатым Фәнил абыйга иде. Ул ике туганым булса да, үз абыем кебек: килә, хәл белешә, мине рәнҗеткән малайларны тукмап китә. Көчле инде, шуңа күрә, чит авылныкы булса да, аңа каршы сүз әйтерлек кеше юк, әллә кайдан танып торалар. Малай чакта күпләр үзләрен рәнҗетергә маташкан кешеләрне: «Әтигә әйтәм», «Абыйга әйтәм!» – дип куркыталар иде. Минем андый кешем юк... Ләкин кайберәүләр: «Аның бит Фәнил абыйсы бар», – дип сугарга күтәргән кулын төшереп җибәрәләр, миңа тимиләр иде. Менә шуңа иң якын кешем итеп күргәнмендер инде, беренче хатымны да аңа яздым. Хат ук та түгел әле ул, открытка дип аталган нәрсә иде. Бәйрәм уңаеннан. «Фәнил абый, котлыйм сине сигезенче март белән...» Миңа алты гына яшь иде әле, дөрес яздым микән дип, әнигә күрсәттем. Ул кычкырып көлеп җибәрде, югалып калуымны күргәч, кочаклап алды: «Улым, маладис язгансың... Тик бу көн – хатын-кызлар бәйрәме, син абыеңны 23 февраль белән котла», – диде ул, башымнан сыйпап. Дәфтәр битенә язылган беренче хатым да шул ук Фәнил абыйга иде. «Абый, теге малайлар мине тагын кыйнадылар, килеп кирәкләрен биреп кит әле...» Бу хатны мин әнигә дә күрсәтмәдем, җибәрмәдем дә. Ул тапшырылмаган хатларның берсе булып үземдә калды.

Хатлар көтеп өзгәләнгән чагым хәтердә. Туган йортымнан иртә чыгып китсәм дә, әнидән хат көтмәдем инде мин. Ул минем өчен җан аямый торган кеше булса да, бераз кырыс холыклы, хат яза торган түгел иде. Аннан соң үсмер чакта берәү дә эти-әнисеннән хат көтеп ятмый инде, һәркем үзенең шәхес икәнен расларга тырыша, хәтта аларның булмавы хәерлерәк кебек тоела. Бөтенләй үк югалтып тормасыннар дип, кайчагында үзең генә хат саласың. Әти-әниләр хәлен үсмер чакта беркем дә аңлый алмый, аны үзең әти-әни булгач кына аңлап үкенәсең. Эх, шулай икән бит ул, шулай итәргә кирәк булган икән дисең.

Мин сөйгән кызымнан хат көтә идем. Күрше авылныкы ул. Җанымның мәхәббәткә тилмереп йөргән бер вакытында очраттым да аннан да кадерлерәгем юк кебек тоелды. Кыш иде ул, янына берничек тә барып булмый кебек иде. Хатлар яздым. Җавабы да килде. Языштык. Их, аның хатын көткән мизгелләр! Гадәттә, сәгать алтылар тирәсендә почтальоннар үтә. Тик урамда буран. Мондый чакта килми дә калалар. Мин көтәм. Минутына кырык тапкыр чыгып капка арасындагы ярыкны карап керәм. Ул вакытта почта яшниге юк, гәҗит-журналларны шунда кыстырып китәләр. Гәҗит-фәлән булмагач, күңел бераз тынычлана төшә, димәк, әле таратмаганнар. Соңрак булачак. Мин күпмедер минут саен капка төбеннән әйләнеп керәм. Юк. Буран. Буран кайчак капкаларны ачып ыргыта. Тәрәзә төпләрендә вәгазь сөйли. Мин хат кына көтәм. Инде йокларга яткач та вакыт-вакыт капка төбеннән урап керәм. Әни минем тышка чыгуымның ешлыгын сизеп: «Улым, син бик еш йөрисең түгелме? Врачка күренергә кирәкмиме?» – дип борчыла. Нинди врач монда? Мин хат көтәм!

Мин үземнең шул чагымны сагынам. Хатлар көткән чакны. Хатлар алып биегәнемне дә, алалмыйча моңсуланганымны да түгел, ә хатлар көткәнемне. Әниемнән, сөйгәнемнән, якыннарымнан. Үземне дә хат итеп тоясым килә. Хаттан да көтеп алынганрак, хаттан да кадерлерәк зат юк чөнки. «Көтеп алынган кунак» дигән тәгъбир бар. Кунакны күп күргән кеше буларак, миңа «көтеп алынган» дигәне кадерле. Әй, сез сизәсезме? Без бүген бер нәрсәне дә көтеп алмыйбыз, күптән көтелгән әйберләр безгә көтмәгәндә килә. Бу сагынуларның да, сюрпризларның да бәясен киметә. Сез үз чорыгызны сизәсезме?

Ә мин хатлар көтәм...

Әле менә почта яшниге дип аталган нәрсәне урам коймасына чыгарып элдем дә... Хатлар көтәм... Утка-суга-газга һәм башкаларга түләүне сораган язулар килә. Алары хат түгел инде аның. Гәҗитләр дә килә. Мин шулар арасыннан конверт эзлим. Акчалы түгел, хатлы конвертлар. Акчалары да юк, конверты да. Ә мин хатлар көтәм. Кайвакытта төн уртасында чыгып карыйм. Юк.

Мин Аның, яшьлегемдә сөйгән ярымның, хатларын көтәм бугай. Ул янымда ята. Тынгысызлап йөргән чакларымда уянып китсә: «Марат, хәлең әйбәтме?» – дип сорый. Хәлем әйбәт.

Тик мин хатлар көтәм...

Марат КӘБИРОВ

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан

ай саен бер бүләк

1 **ЯЗЫЛ!** 2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ЖИБӘР!**

89179270040

info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!** 30 июньгә кадәр газетага язылучылар арасында **ТАНДЫР** уйнатабыз

2022 елның 6–16 июнь көннәрендә газетага ташламалы бәядән язылыш була!

П2435 жомга саны

423 сум 48 тиен

гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга

942 сум 18 тиен

гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

МАЙ АЕНЫҢ БҮЛӘК ИЯЛӘРЕ
Әфган казанын Әлки районының Аккош авылыннан Альбина ХАМӘТШИНА отты.
Тандыр иясе – Казаннан Лилия ГАЙСИНА.
Июнь аенда тагын бер тандыр бүләк итәбез.
Квитанцияләр 5 июльгә кадәр кабул ителә.
7 июль көнне уйнатыла.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 17 июленә хәтле дәвам итә. Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Тулырак: vatantat.ru 16+

Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм затлы!
Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә.
Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре, Зәкиев урамы, 4 нче й., сул канат, 2 нче кат

тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

«АРЧА ОСТАСЫ»

Капка-коймалар, мангал, атынчыклар, бакча өчен урындык-өстәлләр, беседкалар, чардуганнар.

+7-906-326-82-68 Зөлфәт

Реклама



Рәис Габдулла

3 июнь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: тартык, магний, лаз, чалгы, луза, инк, Конг, Гази, Свифт, Отт, дау, ренклод, НАТО, Спартак, иена, Кант, Гафт. **Вертикаль буенча:** леггорн, ашалу, гает, Газиз, ТНТ, Танзания, Кос, пәке, кайчы, спора, ринг, Леонид, тета, Фадлан, ыргыту, кают.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Муса Бигиев Коръәнне нинди телгә тәрҗемә итә?

А) рус;
Б) татар-госманлы;
В) испан.

2 Милләт Мәҗлесе хәзер ничек аталыр иде?

А) палата;
Б) парламент;
В) дума.

3 Иннополис шәһәре ничәнче елда ачылды?

А) 2015;
Б) 2019;
В) 2013.

4 Композитор Фәрит Яруллинга Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе нәрсә өчен бирелә?

А) «Алтынчәч» операсы;
Б) «Мең дә бер кичә» әсәре;
В) «Шүрәле» балеты.

Җаваплар: 1) Б; 2) Б; 3) А; 4) В.

ТӨЗЕЛЕШ һӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ

барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара

ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР

Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.

Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәрү, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.

Пенсионерларга 15-20% ташлама!

Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре һ.б.

Мөрәҗәгать иткән көнне үк килəбез!

тел.: 8 905 199 99 79

Реклама

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 281

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриренең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+